**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 28 июль № 547

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республи-касының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары белән расланган шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары белән расланган шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 бүлектә:

4.2 бүлекчәдә:

4.2.26 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2.26. Микрорайонның иҗтимагый зонасына түбәндәгеләр керә:

мәктәпкәчә белем бирү оешмалары;

белем бирү оешмалары;

хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләре.»;

4.2.41 нче пунктта:

өченче абзацтагы «(мәктәпләр һәм мәктәпкәчә балалар учреждениеләре участокларын исәпкә алмыйча)» сүзләрен «(гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмалары участокларын исәпкә алмыйча)» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта:

«гомуми белем бирү учреждениесе», «мәктәпкәчә балалар учреждениеләре», «учреждение бинасыннан», «мәктәп учреждениеләре һәм мәктәпкәчә учреждениеләр территорияләре» сүзләрен тиешенчә «гомуми белем бирү оешмасы», «мәктәпкәчә белем бирү оешмалары», «оешма бинасыннан», «мәктәп һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмалары территорияләре» сүзләренә алмаштырырга;

4.2.42 нче пунктта «СанПиН 2.4.1.2660-10», «мәктәпкәчә оешмаларда эшләү

тәртибен» сүзләрен тиешенчә «СанПиН 2.4.1.3049-13», «мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында эшләү тәртибен» сүзләренә алмаштырырга;

4.2.48 нче пунктта «мәктәпкәчә оешмаларны урнаштыру», «мәктәпкәчә оешма бинасы», «СанПиН 2.4.1.2660-10», сүзләрен тиешенчә «мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын урнаштыру», «мәктәпкәчә белем бирү оешмасы бинасы», «СанПиН 2.4.1.3049-13» сүзләренә алмаштырырга;

4.2.50 нче пунктның алтынчы абзацында «мәктәпкәчә һәм мәктәп учреждениеләре» сүзләрен «мәктәпкәчә белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

4.3 бүлекчәнең 4.3.1 нче пунктындагы «урта һөнәри һәм югары һөнәри белем бирү объектларын» сүзләрен «һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары объектларын» сүзләренә алмаштырырга;

4.4 бүлекчәдә:

4.4.40 нчы пунктта «мәктәпкәчә балалар учреждениеләре, гомуми белем бирү мәктәпләре, сәламәтлек саклау һәм ял учреждениеләре» сүзләрен «гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, медицина оешмалары, ял йортлары» сүзләренә алмаштырырга;

4.4.46 нче пунктта «югары һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләре» сүзләрен «һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлектә:

5.1 бүлекчәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«5.1. Социаль инфраструктура**

5.1.1. Социаль инфраструктура учреждениеләре, предприятиеләре һәм оешмаларына гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, медицина оешмалары, социаль тәэмин итү оешмалары, яшьләр белән эшләү учреждениеләре, спорт һәм физкультура-сәламәтләндерү учрежденияләре, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре, сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү предприятиеләре, идарә оешмалары һәм учреждениеләре, проект оешмалары, кредит-финанс учреждениеләре һәм элемтә предприятиеләре, фәнни һәм административ оешмалар һәм башкалар (алга таба – хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләре) керә. Бердәм хезмәт күрсәтү системасын булдыру максатларында, барлык милек төрләрендәге һәм формаларындагы хезмәт күрсәтү учреждениеләрен һәм предприятиеләрен шәһәр төзелеше торышын, шәһәр округы һәм җирлек составындагы торак пунктларның планлаштыру структурасын, торак районнарга һәм микрорайоннарга (кварталларга) бүленешне исәпкә алып урнаштырырга кирәк.

Хезмәт күрсәтү учреждениеләрен һәм предприятиеләрен түбәндәге факторларны исәпкә алып урнаштырырга кирәк:

аларның яшәү һәм эшләү урыннарына якынлашуы;

иҗтимагый пассажирлар транспорты челтәре белән элемтә.

5.1.2. Шәһәр торак пунктындагы хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләренең санын, составын һәм сыйдырышлыгын билгеләгәндә, зур шәһәр

торак пунктларына – күчеп килү системасы үзәкләренә күп дигәндә 2 сәгать, кече һәм урта шәһәр торак пунктларына күп дигәндә 1 сәгать бару өчен күп вакыт китү белән чикләнгән зонада урнашкан башка торак пунктлардан килүче халыкны да исәпкә алырга кирәк; шулай ук тарихи җирлекләрдә – туристларны; авыл җирлекләрендә сезонлы халыкны да исәпкә алырга кирәк.

5.1.3. Хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләре санын һәм сыйдырышлыгын, аларның җир кишәрлекләре зурлыгын исәпләгәндә, әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымтаның 4 таблицасында китерелгән тәэмин ителешенең социаль нормативлары буенча кабул итәргә кирәк.

Микрорайонга (кварталга) һәм торак районга хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләре санын, сыйдырышлыгын, аларның җир кишәрлекләре зурлыгын исәпләгәндә, аларны урнаштырганда халыкның төрле төркемнәренең, шул исәптән физик мөмкинлекләре чикләнгән төркемнәр ихтыяҗларын канәгатьләнерү кирәклегеннән чыгып, әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымтаның 4 таблицасында китерелгән тәэмин ителешенең социаль нормативларыннан ким булмаган тәэмин ителешнең социаль нормативларын кабул итеп эш итәргә кирәк.

Әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымтаның 4 таблицасында күрсәтелмәгән хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләре санын, сыйдырышлыгын, аларны урнаштыру һәм җир кишәрлекләре зурлыгын проектлаштыруга йөкләмә буенча билгеләргә кирәк.

5.1.4. Бакчачылык, яшелчәчелек берләшмәләре, дача хуҗалыклары һәм авыл торак пунктларында вакытлыча яшәү белән торак фонды сезонлы халкы өчен хезмәт күрсәтү учреждениеләрен исәпләүне түбәндәге күрсәткечләр буенча, 1000 кешегә исәпләгәндә кабул итәргә кирәк:

сәүдә учреждениеләре – сәүдә мәйданының 80 кв.метры;

көнкүреш хезмәтләре күрсәтү учреждениеләре – 1,6 эш урыны;

янгын деполары – 0,2 янгын автомобиле.

5.1.5. Хезмәт күрсәтү системасын формалаштырганда, учреждениеләр һәм объектлар, шул исәптән көндәлек, вакытлы һәм эпизодик хезмәтләр күрсәтүче учреждениеләр һәм объектлар белән тәэмин ителеш дәрәҗәләре күздә тотылырга тиеш:

көндәлек хезмәтләр күрсәтүче – халык кимендә атнага бер тапкыр бара торган учреждениеләр һәм предприятиеләр яисә халыкның яшәү һәм эш урыннарына якын урнашкан учреждениеләр һәм предприятиеләр;

вакытлы хезмәтләр күрсәтүче – халык кимендә айга бер тапкыр бара торган учреждениеләр һәм предприятиеләр;

эпизодик хезмәтләр күрсәтүче – халык айга бер тапкырдан сирәгрәк бара торган учреждениеләр һәм предприятиеләр (махсуслаштырылган уку йортлары, хастаханәләр, универсаль кибетләр, театрлар, концерт һәм күргәзмә заллары һ.б.).

Хезмәт күрсәтү төрләре буенча объектлар исемлеге әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымтаның 4 таблицасында китерелә.

5.1.6. Шәһәр торак пунктлары территориясендә көндәлек хезмәтләр күрсәтүче социаль әһәмияттәге объектлар белән минималь тәэмин ителеш исемлеге һәм исәп-хисап күрсәткечләре 25 таблицада китерелә.

5.1.7. Микрорайон (квартал) территориясеннән тыш, башка функциональ

билгеләнештәге территорияләр кысаларында урнаштырыла торган торак, катнаш торак урыннар төркемен проектлаштырганда, көндәлек хезмәтләр күрсәтүче объектларны урнаштыру зарур.

Микрорайон составындагы төркемне урнаштырган очракта, көндәлек хезмәтләр күрсәтүче объектлар һәм алар белән тәэмин ителеш күрсәткечләре вакытлы хезмәтләр күрсәтүче объектлар белән тәэмин ителешнең кушылган күрсәткечләренә керә.

25 таблица

Шәһәр торак пунктлары территориясендә
көндәлек хезмәтләр күрсәтүче социаль әһәмияттәге объектлар белән
минималь тәэмин ителеш исемлеге һәм исәп-хисап күрсәткечләре

| Көндәлек хезмәтләр күрсәтүче оешмалар, предприятиеләр һәм учреждениеләр | Үлчәү берәмлекләре | Минималь тәэмин ителеш |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары | 1000 кешегә урын | Торак пунктның демографик структурасына бәйле рәвештә, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары саныннан чыгып:<br>шәһәрләрдә – балаларның 85 проценты,<br>шулардан түбәндәге оешмаларда:<br>гомуми типтагы – балаларның 71 проценты;<br>тәүлек буе эшләүче – 1,2 процент;<br>санаторий тибындагы – 12 процент;<br>коррекцион – 0,8 процент |
| Гомуми белем бирү оешмалары | 1000 кешегә урын | Торак пунктның демографик структурасына бәйле рәвештә, мәктәп белем бирүнең 100 процентыннан чыгып |
| Азык-төлек кибетләре | 1000 кешегә сәүдә мәйданы кв.метры | Барлыгы – 3 нче кушымтадагы 4 таблица нигезендә, шул исәптән 70 кв.метр – хезмәтләр күрсәтү радиусы чикләрендә, калган мәйдан – хезмәтләр күрсәтү радиусыннан читтә, муниципаль район чикләрендә |
| Беренчел кирәк-ярак товарлары кибетләре | 1000 кешегә сәүдә мәйданы кв.метры | Барлыгы – 3 нче кушымтадагы 4 таблица нигезендә, шул исәптән 30 кв.метр – хезмәтләр күрсәтү радиусы чикләрендә, калган мәйдан – хезмәтләр күрсәтү радиусыннан читтә, муниципаль район чикләрендә |
| Даруханә пункты | торак төркемгә объект | 1 |
| Банклар бүлекләре, операцияләр кассасы | операция кассалары саны | 10 – 30 мең кешегә 1 |
| Элемтә бүлеге | торак төркемгә объект | 1 |
| Көнкүреш хезмәтләре күрсәтү предприятиеләре (остаханәләр, | 1000 кешегә эш урыны | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| чәчтарашханәләр һ.б.) | | |
| Кер юу йорты, химик юл белән чистарту кабул итү пункты | торак төркемгә объект | 1 |
| Мәдәният учреждениеләре | 1000 кешегә гомуми мәйдан кв.метры | 50 |
| Көндәлек хезмәт күрсәтүче спорт-тренажер залы | 1000 кешегә идән мәйданы кв.метры | 70 – 80 |
| Яссы спорт корылмалары | 1000 кешегә кв.метр | 1950 |
| Тәртип саклау пункты | торак төркемгә гомуми мәйдан кв.метры | 10 |
| Җәмәгать бәдрәфләре | 1000 кешегә җайланма | 1 |
| Искәрмә: Шәһәр торак пунктларында күп катлы төзелеш территориясендәге яссы спорт корылмалары белән тәэмин ителешне исәпләгәндә, микрорайоннарның торак зонасы составына кергән физкультура белән шөгыльләнү мәйданчыклары исәпкә алына. | | |

5.1.8. Планлаштырылган структура элементларына бәйле рәвештә шәһәр торак пунктының торак йорт салу урыннарында урнаштырыла торган хезмәт күрсәтү оешмалары, учреждениеләре һәм предприятиеләре тарафыннан халыкка хезмәтләр күрсәтү радиусын 26 таблица нигезендә кабул итәргә кирәк.

26 таблица

Шәһәр торак пунктының торак йорт салу урыннарында урнаштырыла торган хезмәт күрсәтү оешмалары, учреждениеләре һәм предприятиеләре тарафыннан халыкка хезмәтләр күрсәтү радиусы

| Хезмәт күрсәтү оешмалары, учреждениеләре һәм предприятиеләре | Хезмәтләр күрсәтү радиусы, метр |
|---|---|
| Түбәндәге йорт салу урынындагы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары:<br>күп катлы;<br>кечкенә шәһәрләрдә, бер катлы, ике катлы йорт салу урынындагы | <br>300<br>500 |
| Белем бирү оешмалары:<br>II – III баскыч укучылары өчен;<br>I баскыч укучылары өчен | <br>750<br>500 |
| Физкультура-сәламәтләндерү дәресләре өчен урыннар | 500 |
| Торак районнарның физкультура-спорт үзәкләре | 1500 |
| Шәһәр торак пунктларында поликлиникалар һәм аларның филиаллары | 1000 |
| Йорт салу урынындагы даруханәләр:<br>күп катлы;<br>аз катлы | <br>500<br>800 |
| Түбәндәге йорт салу урынындагы җирле әһәмияттәге сәүдә, җәмәгать туклауну һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү предприятиеләре:<br>күп катлы;<br>аз катлы | <br><br>500<br>800 |
| Элемтә бүлекләре һәм банклар филиаллары | 500 |
| Искәрмә:<br>1. Башлангыч сыйныфлы белем бирү оешмаларына укучыларның керү юллары магистраль юлларның машиналар йөри торган өлеше белән бер дәрәҗәдә кисешмәскә тиеш. | |

| |
|---|
| 2. Белем бирү оешмалары транспорт йөрү урыныннан түбәндәге ераклыкта урнаштырылырга тиеш: укытуның I баскыч укучылары өчен – 15 минут (бер якка), II – III баскыч укучылары өчен – күп дигәндә 50 минут (бер якка) (СП 42.13330-2011).<br>3. Махсуслаштырылган һәм сәламәтләндерүче мәктәпкәчә белем бирү һәм гомуми белем бирү оешмалары (телләр, математик, спорт һ.б.) тарафыннан хезмәтләр күрсәтү радиусы проектлаштыруга йөкләмә буенча алына. |

5.1.9. Торак биналар, гомуми белем бирү оешмалары, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары һәм медицина оешмалары җир кишәрлекләре чикләреннән шәһәр торак пунктларындагы хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләре җир кишәрлекләре чикләренә кадәр минималь ераклык инсоляция һәм яктыртылу исәпләре, янгынга каршы һәм көнкүрештәге аралыкны саклау нигезендә кабул ителергә тиеш, ләкин 27 таблицада китерелгәннәрдән дә ким түгел.

27 таблица

Торак биналар, гомуми белем бирү, мәктәпкәчә белем бирү һәм медицина оешмалары җир кишәрлекләре чикләреннән хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләре җир кишәрлекләре чикләренә кадәр минималь ераклык

| Хезмәт күрсәтү оешмалары, учреждениеләре һәм предприятиеләре җир кишәрлекләре чикләре | Хезмәт күрсәтү оешмалары, учреждениеләре һәм предприятиеләре биналарыннан (кишәрлекләре чикләреннән) ераклык, метр | | |
|---|---|---|---|
| | кызыл сызыкка кадәр | торак биналарның җир кишәрлекләре чикләренә кадәр | гомуми белем бирү, мәктәпкәчә белем бирү һәм медицина оешмаларының җир кишәрлекләре чикләренә кадәр |
| Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү оешмалары (бина диварлары) | 25 | инсоляция, яктыртылу һәм янгынга каршы таләпләр нормалары буенча | |
| Икенчел чимал кабул итү пунктлары | - | 20 | 50 |
| Янгын деполары | 10 | 50 | 50 |
| Түбәндәге мәйданлы традицион күмү зираты, гектар: | | | |
| 20 гә кадәр; | 6 | 300 | 300 |
| 20 дән 40 ка кадәр | 6 | 500 | 500 |
| Крематорийлар: | | | |
| әзерләү һәм йола процессларыннан башка, бер камералы бер мич белән; | 6 | 500 | 500 |
| мичләр саны бердән артык булганда | 6 | 1000 | 1000 |
| Ябык зиратлар (күмгәннән соң 25 ел үткәч) һәм мемориаль комплекслар, колумбарийлар, кремациядән соң күмү зиратлары | 6 | 100 | 100 |
| Искәрмә:<br>1. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары участоклары шәһәр урамнары һәм кварталара үтү юллары янында булмаска тиеш.<br>2. Икенчел чимал кабул итү пунктлары яшел утыртмалар полосасы белән аерылып куелган һәм аларга автомобиль транспорты өчен керү юллары каралган булырга тиеш.<br>3. Яңадан урнаштырыла торган хастаханәләр участоклары магистраль урамнар янында булмаска тиеш. | | | |

5.1.10. Шәһәр торак пунктларында аз катлы торак йорт салу территорияләрендә халыкка хезмәт күрсәтү учреждениеләрен һәм предприятиеләрен, халыкның төрле социаль-демографик төркемнәре ихтыяҗларын канәгатьләндерү кирәклегеннән чыгып, хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләре санын һәм сыйдырышлыгын исәпләп, башка хезмәт күрсәтү объектларының якынлыгын һәм транспорт элемтәләрен оештыруны исәпкә алып, урамнар, юллар һәм җәяүлеләр юллары челтәре белән бәйләнештә җәмгыяви үзәкләр формалаштыруны күздә тотып проектлаштырырга кирәк.

Аз катлы торак йорт салу территорияләрендә хезмәт күрсәтү учреждениеләрен һәм предприятиеләрен урнаштыру (тәэмин ителеш нормативлары, җәяү бару радиусы, хезмәт күрсәтү объектлары белән тәэмин ителешнең чагыштырма күрсәткечләре һ.б.) әлеге нормативларның 5.1.12 – 5.1.16 пунктлары таләпләре нигезендә кабул ителә.

5.1.11. Кирәкле хезмәт күрсәтү оешмалары, учреждениеләре һәм предприятиеләре исемлеге әлеге нормативларның 4.3.27 пункты нигезендә кабул ителергә тиеш.

5.1.12. Якынча исәпләр өчен, шәһәр торак пунктларында аз катлы торак йорт салу территорияләрендә хезмәт күрсәтү оешмалары, учреждениеләре һәм предприятиеләре сыйфаты һәм сыйдырышлыгы күрсәткечләрен 28 таблица нигезендә кабул итәргә кирәк.

28 таблица

Аз катлы торак йорт салу территорияләрендә хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләре сыйфатын һәм сыйдырышлыгын билгеләү

| Хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләре | Күрсәткечләр | Җир кишәрлекләре зурлыгы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, 1000 кешегә урын | Демографик структура буенча 1 – 6 яшьтәге яшь төркеменнән 85 процент чикләрендә үз эченә ала | Ясле бакчалары сыйдырышлыгы, 1 урынга түбәндәге кв.метр: 100 урынга кадәр – 40, 100 дән артык – 35, ясле бакчалары комплексында 500 дән артык урын – 30 |
| Гомуми белем бирү оешмалары, 1000 кешегә урын | Демографик структура буенча 7 – 18 яшьтәге яшь төркеменнән 100 процент чикләрендә үз эченә ала | Гомуми белем бирү оешмалары сыйдырышлыгы, укучылар:<br>40 тан алып 400 кадәр – 1 укучыга 50 кв.метр;<br>400 дән алып 500 кадәр – 1 укучыга 60 кв.метр;<br>600 дән алып 800 кадәр – 1 укучыга 40 кв.метр;<br>800 дән алып 1100 кадәр – 1 укучыга 33 кв.метр;<br>1100 дән алып 1500 кадәр – 1 укучыга 21 кв.метр;<br>1500 дән алып 2000 кадәр – |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | 1 укучыга 17 кв.метр;<br>2000 артык – 1 укучыга 16 кв.метр |
| Спорт-ял итү комплексы, 1000 кешегә гомуми мәйдан кв.метры | 300 | объектка 0,2 – 0,5 гектар |
| Яссы спорт корылмалары, 1000 кешегә кв.метры | 1950 | Проектлаштыруга йөкләмә буенча |
| Амбулатория-поликлиника учреждениеләре:<br><br>поликлиникалар, бер сменага 100 кешегә бару;<br>амбулаторияләр, 1000 кешегә гомуми мәйдан кв.метры | <br><br><br>22<br><br>50 | сменага 100 тапкыр баруга 0,1 гектар, ләкин түбәндәгеләрдән ким түгел:<br>объектка 0,5 гектар<br><br>объектка 0,2 гектар |
| Даруханәләр, 1000 кешегә гомуми мәйдан кв.метры | 50 | объектка 0,2 – 0,4 гектар |
| Даруханә киосклары, 1000 кешегә гомуми мәйдан кв.метры | 10 | объектка 0,05 гектар яки бина эченә салынган |
| Көнкүреш сәүдә предприятиеләре, 1000 кешегә сәүдә мәйданы кв.метры:<br>азык-төлек кибетләре;<br><br><br><br><br><br><br><br>азык-төлек булмаган товарлар кибетләре | <br><br><br>Барлыгы – 3 нче кушымтаның 4 таблицасы нигезендә, шул исәптән 70 кв.метр – хезмәтләр күрсәтү радиусы чикләрендә, калган мәйдан – хезмәтләр күрсәтү радиусыннан читтә, муниципаль район чикләрендә.<br>Барлыгы – 3 нче кушымтаның 4 таблицасы нигезендә, шул исәптән 30 кв.метр – в хезмәтләр күрсәтү радиусы чикләрендә, калган мәйдан – хезмәтләр күрсәтү радиусыннан читтә, муниципаль район чикләрендә | объектка 0,2 – 0,3 гектар |
| Көнкүреш хезмәтләре күрсәтү предприятиеләре, 1000 кешегә эш урыны | 2 | объектка 0,15 гектар |
| Элемтә бүлеге, объект | 1 | объектка 0,1 – 0,15 гектар |
| Банк бүлеге, 1000 кешегә гомуми мәйдан кв.метры | 40 | |
| Тәртип саклау терәк пункты, объект | 1 | объектка 0,1 – 0,15 гектар |
| Административ үзидарә үзәге, объект | 1 | |
| Искәрмә:<br>1. Гомуми белем бирү оешмалары түбәндәгечә урнаштырыла: төп һәм урта гомуми белем бирү | | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| оешмалары – халкы саны 2 мең кешедән ким булмаган җирлекләрдә, башлангыч гомуми белем бирү оешмалары – халкы саны 500 кешедән ким булмаган җирлекләрдә. | | |
| 2. Поликлиникалар урнаштыруны, норматив ераклыкны саклаганда, якында урнашкан торак массивлар территориясендә күздә тотарга була. | | |

5.1.13. Шәһәр торак пунктларының аз катлы торак йорт салу территорияләрендә хезмәт күрсәтү учреждениеләрен һәм предприятиеләрен урнаштыруны ераклык радиусларын 29 таблицада күрсәтелгәнннәрдән арттырмыйча исәпкә алып гамәлгә ашырырга кирәк.

Объектларны урнаштырганда, норматив ераклык радиусларын саклап, күрше территорияләрдә булган оешмалар, учреждениеләр һәм предприятиеләрне исәпкә алырга кирәк (керү юллары машиналар йөри торган өлеш белән кисешмәскә тиешле I баскыч мәктәпкәчә белем бирү һәм гомуми белем бирү оешмаларыннан гайре).

29 таблица

Аз катлы торак йорт салу территорияләрендә
хезмәт күрсәтү оешмаларын, учреждениеләрен һәм предприятиеләрен урнаштыру

| Халыкка хезмәт күрсәтү оешмалары, учреждениеләре һәм предприятиеләре | Хезмәтләр күрсәтү радиуслары, метр |
|---|---|
| Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары:<br>шәһәрләрдә;<br>кечкенә шәһәрләрдә, бер катлы һәм ике катлы йорт салу урынындагы | <br>300<br>500 |
| Гомуми белем бирү оешмалары:<br>башлангыч сыйныфлар өчен;<br>II – III баскыч укучылары өчен | <br>500<br>750 |
| Физкультура-сәламәтләндерү дәресләре һәм ял итү өчен урыннар | 800 |
| Амбулатория-поликлиника учреждениеләре | 1000 |
| Даруханәләр | 800 |
| Көндәлек файдалану өчен сәүдә һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү предприятиеләре | 800 |
| Элемтә һәм банк бүлекләре, тәртип саклау терәк пункты | 800 |
| Җирле үзидарә үзәге | 1200 |

5.1.14. Шәһәр һәм авыл торак пунктларының аз катлы торак йорт салу территорияләрендә хезмәтләр күрсәтүне оештыру өчен, эшчәнлекнең индивидуаль төрен кулланып, башлыча беренче һәм цоколь (мәктәпкәчә белем бирү оешмаларыннан гайре) катларында урнаштырып һәм бинаның торак өлешләреннән читтә булган керү урыннарын булдырып, торак биналарның эченә салынган яки янына салынган оешмалар, учреждениеләр һәм предприятиеләрне урнаштыру мөмкин. Шул ук вакыта бинаның эченә салынган учреждениеләрнең гомуми мәйданы 150 кв.метрдан артмаска тиеш. Алда әйтелгән учреждениеләр һәм предприятиеләр үзәкләштерүче әһәмияткә ия була ала һәм торак урыннарның үзәк өлешендә урнаштырыла ала.

5.1.15. Эченә салынган һәм янына салынган автомобильләрне ремонтлау һәм вакытлыча файдалануга бирү, көнкүреш техникасын ремонтлау остаханәләре, шулай ук ритуаль хезмәтләр күрсәтү урыннары булган объектларны торак зонаның

чигендә урнаштырырга кирәк.

5.1.16. Халыкның сәламәтлегенә зыян китерүче, бина эченә салынган предприятиеләрне (рентген кабинетлары, аппаратлары (СанПиН 2.6.1.1192-03 таләпләре нигезендә стоматология кабинетларыннан тыш), төзелеш материаллары, москатель-химик материаллар кибетләре һ.б.) аз катлы йорт салу территорияләрендә урнаштыру рөхсәт ителми.

5.1.17. Авыл торак пунктлары территориясендә хезмәт күрсәтү учреждениеләрен һәм предприятиеләрен, 50 кешедән башлап, һәр торак пунктта беренче чиратта кирәкле объектларга һәм җирлекнең административ үзәгендә урнаштырыла торган югарырак дәрәҗәдәге төп объектларга бүлүне күздә тотарга кирәк. Авыл халкына көндәлек хезмәтләр күрсәтү объектлары исемлеге әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымтаның 3 таблицасы нигезендә билгеләнә.

5.1.18. Хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләре белән тәэмин ителешенең кирәкле дәрәҗәсен, халыкның категорияләре буенча үз эченә алу дәрәҗәсен исәпләү һәм җир кишәрлекләренең зурлыклары әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымтаның 4 таблицасы нигезендә билгеләнә.

Әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымтаның 4 таблицасында күрсәтелмәгән хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләре өчен санын, сыйдырышлыгын, аларны урнаштыру шартларын һәм җир кишәрлекләре зурлыгын проектлаштыруга йөкләмә буенча билгеләргә кирәк.

5.1.19. Авыл торак пунктларында хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләре санын, составын һәм сыйдырышлыгын билгеләгәндә, күп дигәндә 30 минут бару өчен күп вакыт китү белән чикләнгән зонада урнашкан башка торак пунктлардан килүче халыкны да исәпкә алырга кирәк.

5.1.20. Авыл торак пунктларында хезмәт күрсәтү объектларын проектлаштырганда, аларның көндәлек, вакытлы һәм эпизодик хезмәтләр күрсәтүче объектларга бүленеш системасын исәпкә алырга кирәк.

5.1.21. Объектлар исемлеге һәм көндәлек (якындагы) хезмәтләр күрсәтүче социаль әһәмияттәге объектлар белән минималь тәэмин ителешнең исәп-хисап күрсәткечләре 30 таблицада китерелә.

30 таблица

Объектлар исемлеге һәм көндәлек (якындагы) хезмәтләр күрсәтүче социаль әһәмияттәге объектлар белән минималь тәэмин ителешнең исәп-хисап күрсәткечләре

| Предприятиеләр һәм учреждениеләр | Үлчәү берәмлекләре | Минималь тәэмин ителеш |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары | 1000 кешегә урын | Демографик структура буенча 1 – 6 яшьтәге яшь төркеменнән 85 процентка кадәр |
| Гомуми белем бирү оешмалары | 1000 кешегә урын | Демографик структура буенча 7 – 18 яшьтәге яшь төркеменнән 100 процентка кадәр |
| Азык-төлек кибетләре | 1000 кешегә сәүдә мәйданы | Барлыгы – 3 нче кушымтаның 4 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | кв.метры | таблицасы нигезендә, шул исәптән 100 кв.метрга кадәр – хезмәтләр күрсәтү радиусы чикләрендә 2000 метр, калган мәйданы – хезмәтләр күрсәтү радиусыннан читтә, муниципаль район чикләрендә |
| Беренчел кирәк-ярак товарлары кибетләре | 1000 кешегә сәүдә мәйданы кв.метры | Барлыгы – 3 нче кушымтаның 4 таблицасы нигезендә, шул исәптән 200 кв.метрга кадәр – хезмәтләр күрсәтү радиусы чикләрендә 2000 метр, калган мәйданы – хезмәтләр күрсәтү радиусыннан читтә, муниципаль район чикләрендә |
| Җәмәгать туклануы предприятиеләре | 1000 кешегә урын | 8 |
| Даруханә пункты | торак төркемгә объект | 1 |
| Элемтә бүлеге | торак төркемгә объект | 1 |
| Банк бүлеге | 1000 кешегә операцион урын | 1 |
| Көнкүреш хезмәтләре күрсәтү предприятиеләре (остаханәләр, ателье, чәчтарашханәләр һ.б.) | 1 000 кешегә эш урыны | 2 |
| Кер юу йорты, химик юл белән чистарту кабул итү пункты | торак төркемгә объект | 1 |
| Мәдәният учреждениеләре | 1000 кешегә гомуми мәйдан кв.метры | 50 |
| Көндәлек хезмәт күрсәтүче спорт-тренажер залы | 1000 кешегә идән мәйданы кв.метры | 70 – 80 |
| Яссы спорт корылмалары | 1000 кешегә кв.метр | 1950 |
| Тәртип саклау пункты | торак төркемгә гомуми мәйдан кв.метры | 10 |
| Җәмәгать бәдрәфләре | 1000 кешегә җайланма | 1 |
| Искәрмә: Халкы саны 200 кешедән аз булган авыл торак пунктлары өчен аз сыйдырышлы, башлангыч сыйныфлар белән кушылган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын күздә тотарга кирәк. Әлеге төр оешмалар белән минималь тәэмин ителешне һәм аларның сыйдырышлыгын җирле шартларга бәйле рәвештә проектлаштыруга йөкләмә буенча кабул итәргә кирәк. | | |

5.1.22. Һәр торак пунктта яшәүчеләрне беренче чиратта кирәкле хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итү 30 минуттан артык булмаган (2 – 2,5 километр) ераклыкта урнашкан җәяүлеләр йөрү урыны чикләрендә гамәлгә ашырылырга тиеш. Югарырак дәрәҗәдәге, шул исәптән вакытлы хезмәтләр күрсәтүче учреждениеләрне урнаштыруны ераклыктагы транспорт белән һәм җәяү йөрү барып җитү ераклыгы 60 минуттан артык булмаган җирлек чикләрендә яисә муниципаль район үзәгендә – вакытлы хезмәтләр күрсәтүче учреждениеләр һәм предприятиеләр тупланган төп үзәктә күздә тотарга кирәк.

Район үзәкләренә хезмәтләр күрсәтү радиусы транспорт белән барып җитү ераклыгы күп дигәндә 60 минут чикләрендә кабул ителә. Әлеге радиусны арттырган

очракта, транспорт белән барып җитү ераклыгы 30 – 45 минут чикләрендә вакытлы хезмәтләр күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләре комплексы составы буенча кирәкле авыл халкына хезмәт күрсәтүче районга караган система булдырырга кирәк.

5.1.23. Авыл торак пунктларында хезмәтләр күрсәтү радиуслары түбәндәгечә кабул ителә:

гомуми белем бирү оешмалары:

укытуның I баскыч укучылары өчен – җәяү барып җитү ераклыгы 2 километрдан артык түгел һәм транспорт белән барып җитү ераклыгы 15 минуттан артык түгел (бер якка);

укытуның II һәм III баскыч укучылары өчен – җәяү барып җитү ераклыгы 4 километрдан артык түгел һәм транспорт белән барып җитү ераклыгы 30 минуттан артык түгел (бер якка).

II – III баскыч укучыларына хезмәтләр күрсәтүнең иң чик радиусы 15 километрдан артмаска тиеш;

сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү предприятиеләре – 2000 метр;

поликлиникалар, амбулаторияләр, фельдшерлык-акушерлык пунктлары һәм даруханәләр – җәяү һәм транспорт белән барып җитү ераклыгы 30 минуттан артык түгел.

5.1.24. Авыл гомуми белем бирү оешмаларыннан 1 километрдан ераграк яшәгән әлеге оешмаларда укучыларга транспорт хезмәте күрсәтелергә тиеш. Укучыларны илтеп кую балаларны йөртү өчен каралган транспортта гамәлгә ашырыла.

Укучыларның тукталышта җыелу урынына җәяү бару ераклыгы 500 метрдан артык булмаска тиеш.

Транспорт тукталышы өч яктан киртәләнгән түбә япма белән җиһазландырыла, юлның машиналар йөри торган өлешеннән барьер белән саклана, аның каты япмасы һәм юл ягыннан кимендә 250 метр күзәтү мөмкинлеге була.

Транспорт хезмәте күрсәтүнең иң чик рөхсәт ителгән урыныннан ераграк яшәүче укучылар өчен, шулай ук начар һава шартлары чорында транспорт килә алмаган очракларда, оешманың гомуми сыйдырышлыгының 10 процент урыны исәбеннән интернат оешмалары күздә тотыла (СП 42.13330-2011).

5.1.25. Хезмәт күрсәтү оешмаларын, учреждениеләрен һәм предприятиеләрен урнаштырганда нормалаштырыла торган санитария-гигиена һәм янгынга каршы таләпләр буенча куркынычсызлык шартлары әлеге нормативларның «Әйләнә-тирә мохитне саклау» һәм «Янгын куркынычсызлыгы» бүлекләре таләпләре нигезендә тәэмин ителә.

5.1.26. Торак биналар, гомуми белем бирү оешмалары, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары һәм медицина оешмалары җир кишәрлекләре чикләреннән авыл торак пунктларындагы хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләре җир кишәрлекләре чикләренә кадәр минималь ераклык инсоляция һәм яктыртылу исәпләре, янгынга каршы һәм көнкүрештәге аралыкны саклау нигезендә кабул ителергә тиеш, ләкин 31 таблицада китерелгәннәрдән дә ким түгел.

31 таблица

Торак биналар, гомуми белем бирү оешмалары, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары һәм медицина оешмалары җир кишәрлекләре чикләреннән
авыл торак пунктларындагы хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләре җир кишәрлекләре чикләренә кадәр минималь ераклык

| Хезмәт күрсәтү оешмалары, учреждениеләре һәм предприятиеләре җир кишәрлекләре чикләре | Хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм предприятиеләре биналарыннан (кишәрлекләре чикләреннән) ераклык, метр | | |
|---|---|---|---|
| | кызыл сызыкка кадәр | торак биналарның җир кишәрлекләре чикләренә кадәр | гомуми белем бирү, мәктәпкәчә белем бирү һәм медицина оешмаларының җир кишәрлекләре чикләренә кадәр |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү оешмалары (бина диварлары) | 10 | инсоляция, яктыртылу һәм янгынга каршы таләпләр һәм янгынга каршы таләпләр нормалары буенча | |
| Икенчел чимал кабул итү пунктла-ры | - | 20 | 50 |
| Янгын деполары | 10 | 50 | 50 |
| Түбәндәге мәйданлы традицион күмү зираты, гектар: 20 гә кадәр; | 6 | 300 | 300 |
| 20 дән 40 ка кадәр | 6 | 500 | 500 |
| Крематорийлар: | | | |
| әзерләү һәм йола процессларыннан башка, бер камералы бер мич белән; | 6 | 500 | 500 |
| мичләр саны бердән артык булганда | 6 | 1000 | 1000 |
| Ябык зиратлар (соңгы тапкыр күмгәннән соң 25 ел үткәч) һәм ме-мориаль комплекслар, колумба-рийлар, кремациядән соң күмү зиратлары | 6 | 100 | 100 |
| Искәрмә:<br>1. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары участоклары хәрәкәт тәртипкә салынмаган урамнар янында булмаска тиеш.<br>2. Икенчел чимал кабул итү пунктлары яшел утыртмалар полосасы белән аерылып куелган һәм аларга автомобиль транспорты өчен керү юллары каралган булырга тиеш.<br>3. Яңадан урнаштырыла торган хастаханәләр участоклары магистраль урамнар янында булмаска тиеш. | | | |

5.1.27. Территориаль планлаштыру документларын һәм территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләгәндә социаль әһәмияткә ия объектларның төп төрләрен гамәлдәге норматив документлар таләпләре, шулай ук әлеге нормативларның 5.1.28 – 5.1.34 пунктлары нигезендә проектлаштырырга кирәк.

5.1.28. Социаль әһәмияткә ия объектлар территорияләреннән сәнәгать, коммуналь, авыл хуҗалыгы предприятиеләренә, транспорт юллары һәм

магистральләргә кадәр ераклыклар әлеге объектлар һәм корылмаларның санитария-саклык зоналарына таләпләр нигезендә билгеләнә.

Объектларны санитария-саклык зоналарында урнаштыру рөхсәт ителми.

5.1.29. Хезмәт күрсәтү предприятиеләренә транспортта һәм җәяү керү урыннары, тыкрыклар, хуҗалык төзелмәләренә, чүп җыю өчен контейнерлар мәйданчыкларына сукмаклар әлеге нормативларның «Транспорт инфраструктурасы зоналары» бүлеге таләпләре нигезендә проектлаштырыла.

5.1.30. Социаль әһәмияткә ия объектлар территорияләре аша магистраль инженер коммуникацияләре (су белән тәэмин итү, канализацияләр, җылылык белән тәэмин итү, электр белән тәэмин итү) үтәргә тиеш түгел.

Объектларның инженерия ягыннан тәэмин ителеше әлеге нормативларның «Инженерия инфраструктурасы зоналары» бүлеге таләпләре нигезендә проектлаштырыла.

5.1.31. Хезмәт күрсәтү оешмаларын, учреждениеләрен һәм предприятиеләрен урнаштырганда нормалаштырыла торган санитария-гигиена һәм янгынга каршы таләпләр буенча куркынычсызлык шартлары әлеге нормативларның «Әйләнә-тирә мохитне саклау» һәм «Янгын куркынычсызлыгы» бүлекләре таләпләре нигезендә тәэмин ителә.

5.1.32. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары биналарын шәһәр урамнарыннан, кварталара үтү юлларыннан тавыш дәрәҗәләрен һәм атмосфера һавасы пычрануын санитария кагыйдәләре һәм нормативлары таләпләренә туры килүне тәэмин итүче ераклыктагы торак микрорайоннарның квартал эчендәге территорияләрендә урнаштырырга кирәк.

Җирлекнең катлаулы рельефларында, балалар өчен уен мәйданчыкларын су басуны һәм аларның пычрануын булдырмас өчен, мәктәпкәчә белем бирү оешмасы участогыннан ташу һәм яңгыр суларын агызуны күздә тотарга кирәк.

Аэрация шартлары буенча, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары участоклары өстенлек итүче җил агымнарының түбән тизлекләре булган, аэродинамик күләгәләр зонасында урнаштырыла.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары төрләре СанПиН 2.4.1.3049-13 нигезендә билгеләнә.

5.1.33. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары белән минималь тәэмин ителеш әлеге нормативларга 3 нче кушымта нигезендә, шулай ук түбәндәгечә кабул ителә:

шәһәр торак пунктлары өчен – 25 таблица буенча;

шәһәр торак пунткларында аз катлы йорт салу территорияләре өчен – 28 таблица буенча.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына кадәр ераклык радиуслары түбәндәгечә кабул ителә:

шәһәр торак пунктлары өчен – 26 таблица буенча;

шәһәр торак пунткларында аз катлы йорт салу территорияләре өчен – 29 таблица буенча;

авыл торак пунктлары өчен – әлеге нормативларның 5.1.23 пункты буенча.

Җир кишәрлегенең мәйданы әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымта таләпләре нигезендә кабул ителә.

5.1.34. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары биналары торак йорт салу

зонасында, предприятиеләр, корылмалар һәм бүтән объектларның санитария-саклык зоналары, санитар аралыклар, гаражлар, автомобиль туктап тору урыннары, автомобиль магистральләре, тимер юл транспорты объектлары, һава транспортының һавага күтәрелү һәм җиргә төшү маршрутларыннан читтә урнаштылырга тиеш.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары биналарын урнаштырганда, инсоляциянең норматив дәрәҗәләрен тәэмин итү һәм бүлмәләрне һәм уен мәйданчыкларын табигый яктырту өчен, торак һәм җәмгыяви биналардан санитар аралыклар сакланырга тиеш.

Яңадан төзелә торган мәктәпкәчә белем бирү оешмалары объектларын аерым торган бинада урнаштыру киңәш ителә. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының сыйдырышлыгы проектлаштыруга йөкләмә нигезендә билгеләнә.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары биналары аерым торган, торак йортлар, административ һәм җәмгыяви билгеләнештәге биналар (сәнәгать предприятиеләренең административ биналарыннан тыш) янына салынган, шулай ук торак йортлар эченә салынган һәм торак йортлар, административ һәм җәмгыяви билгеләнештәге биналар (сәнәгать предприятиеләренең административ биналарыннан тыш) эченә-янына салынган була алалар.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын, балалар өчен аерым керү урыны һәм автомобиль транспорты өчен чыгу (керү) урыны булган аерым киртәләнгән территория булган очракта, торак йортлар эченә салынган биналарда, эченә-янына салынган (яисә янына салынган) биналарда урнаштыру рөхсәт ителә.

5.1.35. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы бинасы өч каттан югары булмаска тиеш.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары биналарының өченче катларында өлкән мәктәпкәчә яшьтәге балалар төркемнәре, шулай ук балалар белән эшләү өчен өстәмә бүлмәләр урнаштыру киңәш ителә.

3 яшькәчә балалар төркемнәре 1 катта урнашкан була.

5.1.36. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы территориясе түбәндәге функциональ зоналарга бүленә:

уен зонасы;

хуҗалык зонасы.

Уен һәм хуҗалык зонасы арасындагы ераклык 3 метрдан ким булмаска тиеш.

5.1.37. Уен территориясе зонасы үз эченә түбәндәгеләрне ала:

төркем мәйданчыклары – һәр төркем өчен индивидуаль – сабыйлар һәм кечкенә яшьтәге балалар өчен (3 яшькә кадәр) 1 балага кимендә 7 кв.метр һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен (3 яшьтән 7 яшькә кадәр) 1 балага кимендә 9 кв.метр исәбеннән һәм төркем изоляциясе принцибын саклап;

физкультура мәйданчыгы (бер яисә берничә).

Ясле яшендәге балалар өчен төркем мәйданчыкларын әлеге төркемнәрдән чыгу урыннарына якын урнаштырылар.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының төркем һәм физкультура мәйданчыклары инсоляциясенең дәвамлылыгы торак һәм җәмгыяви биналар һәм территорияләр урыннары инсоляциясенең һәм аларны кояштан саклауның гигиена кагыйдәләре нигезендә билгеләнә (СанПиН 2.4.1.30049-13).

Балаларны кояштан һәм явым-төшемнәрдән саклау өчен, һәр төркем

мәйданчыгы территориясендә мәйданы бер балага кимендә 1 кв.метр исәбеннән күләгә төшерә торган түбә япма куела. Балалар саны 15 тән әзрәк булган төркемнәр өчен күләгә төшерә торган түбә япма мәйданы 20 кв.метрдан ким булмаска тиеш.

Күләгә төшерә торган түбә япмаларга агачтан яисә башка төзелеш материалларыннан эшләнгән, балалар сәламәтлеге өчен зарары булмаган, җирдән кимендә 15 сантиметр арасы булган идәннәр җәергә кирәк.

Ясле яшендәге һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен күләгә төшерә торган түбә япма өч яктан киртәләнә, киртәнең биеклеге 1,5 метрдан ким булмаска тиеш.

2 яшькәчә ясле яшендәге балалар өчен түбә япмаларны мәктәпкәчә белем бирү оешмасы бинасы янына салырга һәм һава сулау яки йоклау өчен веранда буларак файдаланырга рөхсәт ителә. Биналар янына салынган күләгә төшерә торган түбә япмалар төркемнәрнең бүлмәләренә күләгә төшермәскә һәм табигый яктыртылуны киметмәскә тиеш.

5.1.38. Хуҗалык зонасы ашханәнең производство бүлмәләренә керү ягында урнашырга һәм аның урамнан аерым транспорт керү урыны булырга тиеш.

Шәһәрдә урнашкан (тыгыз) төзелеш шартларында урамнан аерым транспорт керү урыны булмау рөхсәт ителә. Хуҗалык зонасы территориясенә аерым транспорт керү урынын булдыру мөмкинлеге булмаган очракта, автотранспорт хуҗалык мәйданчыгына мәктәпкәчә белем бирү оешмасында балалар булмаган вакытта керә.

Хуҗалык зонасы территориясендә урын җирләрен киптерү һәм келәмнәрне чистарту өчен урыннар күздә тотылырга тиеш.

Хуҗалык зонасы территориясендә яшелчәләр саклау урынын булдыру мөмкин.

Хуҗалык зонасында бинадан 15 метр ким булмаган ераклыкта чүп җыю өчен мәйданчык урнаштырыла. Каты япмалы мәйданчыкта капкачлы контейнерлар куела. Мәйданчыкның зурлыгы контейнерлар нигезенең мәйданыннан зуррак булырга тиеш. Чүп һәм азык-төлек калдыкларын җыю өчен башка махсус ябык конструкцияләрдән файдалану рөхсәт ителә, шул исәптән аларны мәктәпкәчә белем бирү оешмасы территориясе белән чиктәш торак йорт салу урынының контейнерлар мәйданында урнаштырып.

5.1.39. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары территориясен яшелләндерү төзелеш булмаган территория мәйданының кимендә 50 проценты исәбеннән күздә тотыла. Яшел утыртмалардан төркем мәйданчыкларын бер-берсеннән һәм төркем мәйданчыкларын хуҗалык зонасыннан аерып кую өчен файдаланалар. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы территориясен урман һәм бакча массивлары чигендә урнаштырган очракта, яшелләндерү мәйданын 10 процентка киметү рөхсәт ителә.

Шәһәрдә урнашкан (тыгыз) төзелеш шартларында төзелеш булмаган территория мәйданын яшелләндерүне 20 процентка кадәр киметү рөхсәт ителә.

Агачлар мәктәпкәчә белем бирү оешмасы бинасыннан – 15 метрдан, куаклар 5 метрдан ким булмаган ераклыкта утыртыла.

Территорияне яшелләндерү вакытында, балалар арасында агулану очракларын булдырмау максатларында, агулы җимешле агачлар һәм куаклар, шулай ук чәнечкеле куаклар утыртылмый.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы территориясе периметры буенча койма һәм яшел утыртмалар полосасы белән әйләндереп алына.

5.1.40. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары биналары салкын һәм кайнар су белән тәэмин итү системалары, канализация белән җиһазландырылган булырга тиеш. Мәктәпкәчә оешмаларда су белән тәэмин итү һәм канализация үзәкләштерелгән булырга тиеш.

Торак пунктта үзәкләштерелгән су (салкын һәм кайнар) белән тәэмин итү булмаган очракта, мәктәпкәчә белем бирү оешмасында азык-төлек блогына, медицина блогы бүлмәләренә, кер юу йортына (кер юу бүлмәсенә), барлык төркемнәрнең бәдрәфләренә су бирү тәэмин ителә.

Канализация үткәрелмәгән районнарда, пычрак су чокырын яки локаль чистарту корылмаларын булдыру шарты белән, мәктәпкәчә оешмалар биналарын эчке канализация белән тәэмин итәләр.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары биналары, җәмәгать биналарында һәм корылмаларында ягып җылыту, җилләтү һәм кондиционердан файдаланып һаваны алыштыруга куелган таләпләр нигезендә, ягып җылыту һәм җилләтү системалары белән җиһазландырыла. Күчереп йөртелә торган җылыту җайланмаларыннан, шулай ук инфракызыл нурланышлы җылыту җайланмаларыннан файдалану рөхсәт ителми.

5.1.41. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы территориясенә транспортта һәм җәяүле керү урыннары, тыкрыклар, хуҗалык төзелмәләренә, чүп җыю өчен контейнерлар мәйданчыкларына сукмаклар каты япмалы булырга тиеш (асфальт, бетон һ.б.).

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы территориясендә терәк-хәрәкәт аппаратында кимчелекләр булган балалар өчен сукмаклар һәм тротуарларның авышлыгы 5 процентган артык түгел, киңлеге кимендә 1,6 метр күздә тотыла. Борылышларда һәм һәр 6 метр саен аларның ял итү өчен мәйданчыклары булырга тиеш.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы территориясендә, балаларның хәрәкәт итү куркынычсызлыгы өчен, сукыр һәм начар күрүче балалар өчен һава сулап йөрү юлының киңлеге 3 метрдан ким булмаска һәм ике дәрәҗәдә ике яклап киртәләп алынган булырга тиеш: биеклеге 90 сантиметрлы култыкса һәм 15 сантиметр биеклектә планка.

Киртәләр балалар йөргәндә комачау итәрлек барлык предметлар өчен күздә тотыла: агачлар, куаклар, баганалар һ.б.

Борылышлар, юл чатлары, биналар, баганалар янында һәм башка киртәле урыннарда юлларның эре бөртекле структуралы япмасы булырга тиеш, һәм аларның кытыршы өслеге йөрү тизлеген киметер өчен билге буларак хезмәт итә. Асфальт җәелгән юлларның киңлегенә бәйле рәвештә дугасыман профиле булырга тиеш (юлның уртасы кырый якларыннан 5 – 15 сантиметрга биегрәк булып тора).

5.1.42. Яңадан төзелә торган мәктәпкәчә белем бирү оешмалары биналары шәһәр урамнарыннан, кварталара үтү юлларыннан тавыш дәрәҗәләрен һәм атмосфера һавасы пычрануын санитария кагыйдәләре һәм нормативлары таләпләренә туры килүне тәэмин итүче ераклыктагы торак микрорайоннарның квартал эчендәге территорияләрендә урнаштырыла (СанПиН 2.4.2.2821-10).

5.1.43. Гомуми белем бирү оешмалары белән минималь тәэмин ителеш әлеге нормативларга 3 нче кушымта нигезендә, шулай ук түбәндәгечә кабул ителә:

шәһәр торак пунктлары өчен – 25 таблица буенча;

шәһәр торак пунткларында аз катлы йорт салу территорияләре өчен – 28 таб-

лица буенча.

Гомуми белем бирү оешмаларына кадәр ераклык радиуслары түбәндәгечә кабул ителә:

шәһәр торак пунктлары өчен – 26 таблица буенча;

шәһәр торак пунткларында аз катлы йорт салу территорияләре өчен – 29 таблица буенча;

авыл торак пунктлары өчен – әлеге нормативларның 5.1.23 пункты буенча.

Гомуми белем бирү оешмаларын проектлаштырганда җир кишәрлекләренең мәйданнары әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымтаның 4 таблицасы таләпләре нигезендә кабул ителә.

5.1.44. Яңадан төзелә торган гомуми белем бирү оешмаларының сыйдырышлыгы бер генә сменада уку өчен исәпләнгән булырга тиеш (СанПиН 2.4.2.2821-10).

5.1.45. Участок территориясе койма белән һәм аның буйлап яшел утырмалар белән әйләндереп алынган булырга тиеш.

Участокны яшелләндерү территориясе мәйданының кимендә 50 проценты исәбеннән күздә тотыла. Гомуми белем бирү оешмасы территориясен урман һәм бакча массивлары чигендә урнаштырган очракта, яшелләндерү мәйданын 10 процентка киметү рөхсәт ителә. Агачлар гомуми белем бирү оешмалары биналарыннан – 15 метрдан, куаклар 5 метрдан ким булмаган ераклыкта утыртыла.

Территорияне яшелләндерү вакытында, агулану очракларын булдырмау максатларында, агулы җимешле агачлар һәм куаклар утыртылмый.

5.1.46. Гомуми белем бирү оешмасы территориясе түбәндәге зоналарга бүленә: ял итү, физкультура-спорт һәм хуҗалык зонасы. Уку-укыту-тәҗрибә зонасын бүлеп чыгару да рөхсәт ителә.

Уку-укыту-тәҗрибә зонасын оештырганда физкультура-спорт зонасын һәм ял итү зонасын кыскарту рөхсәт ителми.

Функциональ зоналар мәйданын 32 таблица нигезендә 1 сыйныфка карата исәп-хисап күрсәткечләре буенча кабул итәргә киңәш ителә.

Физкультура-спорт зонасын спорт залы ягыннан урнаштыру киңәш ителә. Физкультура-спорт зонасын уку-укыту биналарының тәрәзәләре ягыннан урнаштырганда, уку-укыту биналарындагы тавыш дәрәҗәләре торак, җәмгыяви биналар бүлмәләре һәм торак йорт салу урыннары гигиена нормативларыннан артмаска тиеш.

Гомуми белем бирү оешмаларын проектлаштырганда һәм төзегәндә, озайтылган көн төркемнәренә йөрүче укучыларның хәрәкәтле уеннары һәм ялы өчен, шулай ук саф һавада чаралар үткәрүне күздә тотучы белем бирү программаларын гамәлгә ашыру йөзеннән, территориядә ял итү зонасын булдыруны исәптә тотарга кирәк.

Хуҗалык зонасы ашханәнең производство бүлмәләренә керү ягында урнашырга һәм аның урамнан аерым транспорт керү урыны булырга тиеш.

5.1.47. Хуҗалык зонасы территориясендә, калдыкларны җыю өчен, чүп җыю җайланмалары (контейнерлар) урнаштырылган мәйданчык булдырыла. Мәйданчык азык-төлек блогына керү урыныннан һәм укыту бүлмәләре, кабинетлары тәрәзәләреннән 25 метрдан ким булмаган ераклыкта урнаштырыла һәм зурлыгы

контейнерлар нигезе мәйданыннан һәрьяклап 1 метрга зуррак булган, су үткәрми торган каты япма белән җиһазландырыла. Чүп җыю җайланмаларының тыгыз итеп ябыла торган капкачлары булырга тиеш.

5.1.48. Гомуми белем бирү оешмаларында су белән тәэмин итү һәм канализация – үзәкләштерелгән, җылылык белән тәэмин итү ТЭЦ, район яки җирле казаннар бинасыннан булырга тиеш.

Үзәкләштерелгән канализация челтәре булмаган очракта, локаль чистарту корылмалары белән җирле канализация системалары проектлаштырыла.

5.1.49. Интернат оешмаларын (ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен балалар йортлары һәм интернат-мәктәпләр) шәһәр округы, шәһәр җирлеге составындагы торак пунктларда аерымланган җир кишәрлекләрендә урнаштырырга кирәк. Балалар йортларын гомуми белем бирү оешмалары янында, аларны яңадан төзегәндә 500 метрдан артык булмаган җәяү барып җитү ераклыгы радиусын исәпкә алып урнаштырырга кирәк.

Интернат оешмаларын проектлаштырганда җир кишәрлекләрен урнаштыруны әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымта таләпләре нигезендә кабул итәргә кирәк.

5.1.50. Интернат оешмаларының җир кишәрлекләре мәйданы, аларның сыйдырышлыгына бәйсез рәвештә, хуҗалык зонасы мәйданын һәм төзелеш мәйданын санамыйча, бер тәрбияләнүчегә 150 кв.метрдан ким булмаска тиеш.

5.1.51. Интернат оешмаларында йоклау һәм укыту корпуслары арасындагы ераклык – 50 метран артык, төп биналардан хуҗалык зонасына кадәр – 100 метрдан ким, автомагистральләргә кадәр – 150 метрдан ким, җирле әһәмияттәге юлларга кадәр ераклык 30 метрдан ким булмаска тиеш.

Бинага керү урыннары, тәрбияләнүчеләрнең участокта хәрәкәт итү юллары транспорт үтү юллары белән кисешмәскә тиеш.

32 таблица

## Функциональ зоналар мәйданын билгеләү

| Т/с | Зоналар | Үлчәү берәмлеге | Түбәндәге белем бирү оешмаларындагы мәйдан | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | башлангыч гомуми белем бирү | төп гомуми белем бирү | урта гомуми белем бирү һәм интернат оешмаларында | | | |
| | | | 1 объект (4 сыйныф) | 1 объект (9 сыйныф) | 1 объект (11 сыйныф) | 2 объект (22 сыйныф ) | 3 объект (33 сыйныф) | 4 объект (22+22 сыйныф) |
| 1 | Физкультура-спорт зонасы | 1 сыйныфка зонага кв.метр | 850/213 | 5450/605 | 5610/510 | 6140/280 | 7760/235 | 7920/180 |
| 2 | Уку-укыту-тәҗрибә зонасы | 1 сыйныфка зонага кв.метр | 240/60 | 1008/112 | 1200/109 | 1430/65 | 1980/60 | 2508/57 |
| 3 | Ял итү зонасы | 1 сыйныфка зонага кв.метр | 480/120 | 700/78 | 700/78 | 1400/64 | 2100/64 | 2800/64 |
| 4 | Хуҗалык зонасы | 1 сыйныфка зонага кв.метр | 500/125 | 500/56 | 500/45 | 625/28 | 750/23 | 750/17 |
| Оешмага барлыгы | | 1 сыйныфка зонага кв.метр | 2070/518 | 7658/851 | 8010/728 | 9595/436 | 12590/382 | 13378/318 |

5.1.52. Традицион типтагы интернат оешмаларының сыйдырышлыгы 300 урыннан артык булмаска тиеш, балалар йортларының оптималь сыйдырышлыгы – 60 урын.

5.1.53. Интернат оешмаларын – аерым торган биналарда, мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен балалар йортларын – 2 каттан биек булмаган биналарда, мәктәп яшендәге балалар өчен һәм катнаш типтагы балалар йортларын һәм интернат-мәктәпләрен 3 каттан биек булмаган биналарда урнаштырырга кирәк.

5.1.54. Җир кишәрлеге коры, яхшы җилләтелә һәм инсоляцияләнә торган булырга тиеш, аның икедән ким булмаган транспортта керү урыны (төп һәм хуҗалык), уңайлы керү юллары һәм кимендә 1,6 метр биеклектә киртәсе булырга тиеш.

5.1.55. Участокны яшелләндерү интернат оешмасы территориясе гомуми мәйданының кимендә 50 проценты исәбеннән күздә тотыла.

Периметр буенча урам ягыннан – 6 метр, башка яклардан 1,5 метр киңлектәге яшел утыртмалар полосасын күздә тотарга кирәк.

Агачлар бинадан – 10 метрдан, куаклар 5 метрдан ким булмаган ераклыкта утыртыла.

Территорияне яшелләндерү вакытында, агулану очракларын булдырмау максатларында, агулы җимешле агачлар һәм куаклар утыртылмый.

5.1.56. Интернат оешмаларының җир кишәрлегендә түбәндәге функциональ зоналар проектлаштырыла:

төзелеш зонасы;

физкультура-спорт;

уку-укыту-тәҗрибә;

ял итү зонасы;

хуҗалык зонасы.

Торак урыннарның составы һәм мәйданнары СК 2.4.990-00 нигезендә билгеләнәләр.

Бинаны тыгыз төзелеш шартларында урнаштырган очракта, җир кишәрлеге зоналарының составы проектлаштыруга йөкләмә буенча билгеләнә.

Функциональ зоналар мәйданын 32 таблица нигезендә 1 сыйныфка карата исәп-хисап күрсәткечләре буенча кабул итәргә киңәш ителә.

5.1.57. Катнаш типтагы интернат оешмаларында мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен төркем мәйданчыклары зонасы аерып чыгарыла. Төркем мәйданчыгының мәйданы 1 балага кимендә 7,2 кв.метр исәбеннән кабул ителә.

5.1.58. Авыл торак пунктларында урнашкан интернат оешмалары өчен әлеге оешмалар янында ярдәмче хуҗалык зонасы аерып чыгарыла. Шул ук вакытта ярдәмче хуҗалыклардан торак биналарга кадәр ераклык, җирле шартларны исәпкә алып, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе белән килештерелә.

5.1.59. Физкультура-спорт зонасы мәйданчыклары җайланмалары һәм җиһазы балаларның буена һәм яшенә туры килергә, уеннар һәм дәресләр вакытында балаларның җәрәхәтләнү мөмкинлеген булдырмаска тиеш.

Физкультура-спорт зонасын интернат оешмалары бинасының уку-укыту

бүлмәләре тәрәзәләре ягыннан урнаштыру киңәш ителми.

Туп уеннары һәм спорт снарядларын ыргыту мәйданчыкларын бина тәрәзәләреннән кимендә 25 метр ераклыкта урнаштырырга кирәк; мәйданчыклар 3 метр биеклектәге киртәләр белән әйләндереп алынган очракта, әлеге ераклык 15 метрга кадәр киметелә ала, башка төр физкультура-спорт дәресләре өчен мәйданчыклар 10 метрдан ким булмаган ераклыкта урнаштырылырга тиеш.

5.1.60. Ял итү зонасы яшелләндерелгән һәм тавыш чыганакларыннан (спорт мәйданчыклары, автомобиль туктап тору урыннары, остаханәләр) ераклаштырылган булырга тиеш.

5.1.61. Хуҗалык зонасы мәйданы 1 кешегә кимендә 3 кв.метр исәбеннән кабул ителергә тиеш.

Хуҗалык зонасы җир кишәрлегенең чигендә, төркем һәм физкультура мәйданчыкларыннан читтә урнаштырылырга һәм калган территориядән яшел утыртмалар белән аерып куелырга тиеш.

Хуҗалык зонасының урамнан аерым транспорт керү урыны булырга тиеш.

5.1.62. Хуҗалык зонасында чүп җыю җайланмалары өчен интернат оешмасы бинасыннан кимендә 25 метр ераклыкта бетон белән капланган мәйданчык каралган булырга тиеш. Мәйданчык зурлыгы чүп җыю җайланмалары нигезе мәйданыннан һәрьяклап 1,5 метрга зуррак булырга тиеш.

5.1.63. Интернат оешмаларында су белән тәэмин итү һәм канализация – үзәкләштерелгән, җылылык белән тәэмин итү ТЭЦ, җирле казаннар бинасыннан булырга тиеш.

Автоном ягып җылыту рөхсәт ителә.

Үзәкләштерелгән суүткәргеч һәм канализация челтәрләре булмаган очракта, җирле су белән тәэмин итү һәм канализация системалары проектлаштырыла.

5.1.64. Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын (балалар иҗаты йортлары, яшь техниклар, яшь натуралистлар, яшь туристлар станцияләре, балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләре, балалар сәнгать мәктәпләре, музыка, сәнгать, хореография мәктәпләре) торак пунктлар территориясендә, аларны яшәү һәм уку урыннарына якынайтып, кагыйдә буларак, иҗтимагый пассажирлар транспорты челтәре белән бәйләнештә иҗтимагый үзәкләр составында урнаштырырга кирәк.

5.1.65. Балаларга өстәмә белем бирү оешмалары сыйдырышлыгы, шулай ук аларның җир кишәрлекләре мәйданнары әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымта нигезендә билгеләнә.

Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларына кадәр ераклык радиуслары түбәндәгечә кабул ителә:

шәһәр торак пунктлары өчен – 500 – 1000 метр;

авыл торак пунктлары өчен – проектлаштыруга йөкләмә буенча.

Киңәш ителгән транспортта барып җитү ераклыгы – күп дигәндә 30 минут (бер якка).

5.1.66. Балаларга өстәмә белем бирү оешмалары биналарыннан кызыл сызыкка, торак һәм җәмгыяви биналар диварларына кадәр ераклык гомуми белем бирү мәктәпләре биналарына кебек кабул ителә.

5.1.67. Участок территориясе 1,2 – 1,5 метр биеклектәге койма белән яки яшел утыртмалар белән әйләндереп алынган булырга тиеш.

Участокны яшелләндерү территориясе мәйданының кимендә 50 проценты исәбеннән күздә тотыла.

Участокны яшелләндерү вакытында, агулану очракларын булдырмау максатларында, агулы җимешле агачлар һәм куаклар утыртылмый.

5.1.68. Хуҗалык зонасында чүп җыю җайланмалары өчен интернат оешмасы бинасыннан кимендә 25 метр ераклыкта бетон белән капланган мәйданчык каралган булырга тиеш.

Хуҗалык зонасында чүп җыю җайланмаларын бина тәрәзәләреннән һәм ишекләреннән кимендә 25 метр ераклыкта куярга кирәк.

5.1.69. Һөнәри белем бирү оешмаларын мәстәкыйль җир кишәрлегендә, тавыш чыганакларыннан, атмосфера һавасы пычранудан ышык якта урнаштырырга кирәк.

5.1.70. Уку-укыту биналарын 4 каттан да биек итмичә проектлаштырырга һәм шәһәр торак пунктларында – кимендә 25 метрга һәм авыл торак пунктларында – кимендә 10 метрга кызыл сызыктан читкә китеп урнаштырырга кирәк.

Һөнәри белем бирү оешмаларын проектлаштырганда җир кишәрлекләре мәйданнары әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымта нигезендә билгеләнә.

5.1.71. Җир кишәрлегендә түбәндәге зоналар күздә тотылырга тиеш:

уку-укыту зонасы;

производство зонасы;

спорт зонасы;

хуҗалык зонасы;

торак зона (укучылар өчен тулай торак булганда). Тулай торакны уку-укыту корпусы белән бер участокта урнаштыру максатка ярашлы санала.

Авыл хуҗалыгы профилендәге һәм транспорт чараларын өйрәнүгә бәйле башка профильдәге һөнәри белем бирү оешмаларында, транспорт чараларын ремонтлау, сынау һәм хезмәтләр күрсәтү өчен биналарны һәм корылмаларны урнаштыру өчен төп участоктан тыш, уку-укыту хуҗалыгы зонасы да күздә тотылырга тиеш. Төзелеш профилендәге, автомобиль, тимер юл, авыл хуҗалыгы һөнәри белем бирү оешмаларында участокларда яисә алар янында уку-укыту полигоннарын (җәяү барып җитү ераклыгы 30 минуттан артык түгел) булдыру зарур. Уку-укыту полигоннары мәйданы участокның нормалаштырыла торган зурлыгына керми һәм технологик таләпләр белән билгеләнә.

Хуҗалык зонасы участокның башка зоналарыннан аерымланган һәм аның урамга аерым транспорт чыгу урыны булырга тиеш.

5.1.72. Торак пунктта берничә һөнәри белем бирү оешмасын урнаштырганда, аларның профильләрен исәпкә алып, бердәм ярдәмче хуҗалыгы, уртак уку-укыту биналары, спорт корылмалары, хезмәт күрсәтү учреждениеләре һәм тулай торaклары булган уку-укыту үзәкләре төзеп, аларны берләштерергә кирәк.

Уку йортларын берләштергәндә һәм уку-укыту үзәкләрен төзегәндә, җир кишәрлекләренең зурлыгын уку-укыту үзәкләре сыйдырышлыгына, укучылар санына түбәндәгечә бәйле рәвештә, киметергә киңәш ителә:

1500 дән алып 2000 гә кадәр – 10 процентка;

2000 нән алып 3000 гә кадәр – 20 процентка;

3000 нән алып –30 процентка.

Торак зона, уку-укыту һәм ярдәмче хуҗалыклар, полигоннар, автодром һәм

тракторoдромнар зурлыгы әлеге күләмгә керми.

5.1.73. Участок территориясе яшелләндерелгән һәм 1,2 метрдан ким булмаган биеклектәге койма белән әйләндереп алынган булырга тиеш.

Җир кишәрлеген яшелләндерү мәйданы участок мәйданының кимендә 50 процентын тәшкил итәргә тиеш. Агачлар уку-укыту биналары тәрәзәләреннән – 15 метрдан, куаклар 5 метрдан ким булмаган ераклыкта утыртылырга тиеш.

5.1.74. Һөнәри белем бирү оешмаларында су белән тәэмин итү һәм канализация – үзәкләштерелгән, җылылык белән тәэмин итү ТЭЦ, район яки җирле казаннар бинасыннан булырга тиеш.

Авыл торак пунктларында һәм кечкенә шәһәр торак пунктларында үзәкләштерелгән канализация челтәре булмаган очракта, локаль чистарту корылмалары белән җирле канализация системаларын проектлаштырырга кирәк.

5.1.75. Югары белем бирүче мәгариф оешмаларына бүленеп бирелә торган җир кишәрлекләре, торак пунктның инженерия, транспорт һәм социаль инфраструктуралары белән функциональ бәйләнешне исәпкә алып, уку-укыту-фәнни, торак һәм хуҗалык-көнкүреш биналары һәм корылмалары тулы комплексын урнаштыруны тәэмин итәргә тиеш.

Югары белем бирүче мәгариф оешмаларын проектлаштырганда җир кишәрлекләренең мәйданнары әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымтаның 4 таблицасы нигезендә билгеләнә.

Югары белем бирүче мәгариф оешмалары биналарын зур тизлектә йөрү өчен каралган юллар һәм магистраль урамнар янында урнаштырганда, машина йөри торган өлеш читеннән кимендә 50 метрга читкә китүне күздә тотарга кирәк, шул ук вакытта тулай торакларны территориянең эчендә урнаштырырга киңәш ителә.

Уку-укыту биналарыннан кызыл сызыкка кадәр ераклык 15 метрдан ким булмаска тиеш.

Гомуминститут хезмәтләре белән административ-иҗтимагый үзәкнең барлык уку-укыту корпуслары, шулай ук җәмәгать транспорты тукталышлары арасында җәяүлеләр өчен юлны чыгу урыннары булырга тиеш.

5.1.76. Югары белем бирүче мәгариф оешмаларында студентлар саны 10 мең кешегә кадәр исәпләнгән булганда, уку-укыту зонасы территориясенең зурлыгы 600 метрдан артык булмаска тиеш, һәм бу теләсә кайсы корпуска 10 минутта җәяү барып җитү мөмкинлеген тәэмин итә (лекцияләр арасындагы тәнәфес вакытында).

Югары белем бирүче эре мәгариф оешмаларында уку-укыту зонасы территориясенең зурлыгы 2 километрдан артык булырга мөмкин, шуңа күрә җәяү барып җитү мөмкинлеге (800 метр) бер-ике факультет белән генә чикләнгән булу ихтимал.

5.1.77. Торак зона участогы мәйданы тулай торакларда яшәүче студентлар, аспирантлар һәм әзерлек бүлеге тыңлаучыларының гомуми санына карап исәпләнә (башка шәһәрләрдән килүчеләрне кабул итүне күздә тотып). Тулай торактагы 1000 яшәүчегә карата мәйданның чагыштырма күрсәткече катлар төзелешенә бәйле кабул ителә:

5 – 6 кат – 3 гектар;

9 – 10 кат – 2 гектар;

12 кат һәм югарырак – 1,5 гектар.

5.1.78. Югары белем бирүче мәгариф оешмаларының спорт зонасын уку-укыту һәм торак зоналары янында урнаштырырга кирәк.

Югары белем бирүче мәгариф оешмасы комплексын 2000 кешегә кадәр исәпләнгән студентлар саны белән проектлаштырганда, уку-укыту зонасыннан җәяү барып җитү ераклыгы радиусын саклау шарты белән спорт зонасын башка һөнәри белем бирү оешмаларының спорт зоналары белән берләштерергә киңәш ителә.

5.1.79. Читтән торып уку формасындагы югары белем бирүче мәгариф оешмалары өчен уку-укыту зонасы участогы мәйданы – 1000 дип исәпләнгән студентлар санына 2,5 – 3 гектар, хуҗалык зонасы участогы мәйданы 1000 дип исәпләнгән студентлар санына – 0,5 гектар исәбеннән билгеләнә. Читтән торып уку формасындагы белем бирү оешмаларында спорт зонасы күздә тотылмый.

5.1.80. Хуҗалык зонасы ашханәгә һәм тулай торакка хезмәткәрләр өчен керү урыны белән, шулай ук тәҗрибә-производство корпуслары белән уңайлы бәйләнештә урнаштырылырга тиеш. Хуҗалык зонасы составына хуҗалык ишегалды, бушату мәйданчыклары белән автомобиль транспортын куеп тору урыны, шулай ук склад биналары керә.

5.1.81. Территорияне яшелләндерү мәйданы гомуми мәйданының кимендә 30 – 50 процентын тәшкил итәргә тиеш.

Югары белем бирүче мәгариф оешмасын урман массивлары янында урнаштырганда, шулай ук төзекләндерү вакытында, яшел утыртмалар мәйданын 30 процентка кадәр киметү рөхсәт ителә.

5.1.82. Дәвалау-профилактика оешмалары (алга таба – ДПО) СанПиН 2.1.3.2630-10 таләпләре нигезендә урнаштырыла.

ДПО урнаштыру участогында туфрак санитария-химия, микробиология, паразитология күрсәткечләре һәм радиация факторы буенча гигиена нормативларына туры килергә тиеш, атмосфера һавасында зарарлы матдәләр булу, электромагнит нурланышлары, тавыш, вибрация, инфратавыш дәрәҗәләре гигиена нормативларыннан артмаска тиеш.

5.1.83. Психиатрия, инфекцион, шул исәптән туберкулез профилендәге стационарлар торак төзелеш территориясеннән 100 метрдан ким булмаган ераклыкта урнаштырыла. Әлеге профильдәге 1000 һәм күбрәк койкага стационарларны яшел зонада урнаштыру киңәш ителә.

5.1.84. ДПО участогында аның белән функциональ бәйләнештә булмаган оешмалар биналары урнаштырылырга тиеш түгел. ДПО территориясендә яки аның янәшәсендә кунакханәләр яисә амбулатория тикшерүенә килгән пациентлар һәм/яки озата килгән затлар өчен пансионатлар күздә тоту максатка ярашлы санала.

5.1.85. Торак һәм җәмгыяви биналарда, аерым керү урыны булганда, түбәндәгеләрне урнаштыру рөхсәт ителә:

бер сменага күп дигәндә 100 тапкыр бару мөмкин булган амбулатория-поликлиника ДПО, фельдшерлык-акушерлык пунктларын, көндезге стационарлы оешмаларны кертеп;

стоматология кабинетлары, стоматология амбулатория-поликлиника оешмалары, шул исәптән составларында көндезге стационарлар булган.

Торак биналарның цоколь катларында түбәндәгеләрне урнаштыру рөхсәт ителә:

табиблар кабул итү кабинетлары (1 метрдан арттырмыйча эчкә кереп һәм табигый яктыртылу коэффициентының нормалаштырылган мәгънәсен саклап);

стоматология медицина оешмалары;

фельдшерлык-акушерлык пунктлары, амбулаторияләр.

5.1.86. Торак һәм җәмгыяви биналарда, дерматологның амбулатория-поликлиника консультация кабул итүеннән тыш, йогышлы (шул исәптән туберкулез белән) авыручыларга ярдәм күрсәтүче ДПО урнаштыру рөхсәт ителми.

Торак биналарда алкоголь һәм наркотикларга бәйлелек белән авыручы затларга ярдәм итүче ДПО урнаштыру рөхсәт ителми.

Торак биналарда һәм аларның эченә-янына салынган урыннарда микробиология лабораторияләре (бүлекләре), магнит-резонанс томографиясе бүлекләре урнаштыру рөхсәт ителми.

Ионлаштыручы нурланышлар чыганакларын эксплуатацияләү оешмаларын урнаштыруга таләпләр радиацион куркынычсызлык нормалары һәм әлеге эшчәнлек төренә санитария-гигиена таләпләре нигезендә билгеләнә.

5.1.87. Медицина оешмалары сыйдырышлыгы, шулай ук аларның җир кишәрлекләре мәйданнары әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымтаның 4 таблицасы нигезендә билгеләнә.

Медицина оешмаларына кадәр ераклык радиуслары түбәндәгечә кабул ителә:

шәһәр торак пунктлары өчен – 26 таблица буенча;

шәһәр торак пунктларында аз катлы йорт салу территорияләре өчен –29 таблица буенча;

авыл торак пунктлары өчен – әлеге нормативларның 5.1.23 пункты буенча.

Барлык типтагы стационарлар, поликлиникалар, амбулаторияләр, стационары булмаган диспансерлар, шулай ук хастаханәләр, бала табу йортлары җир кишәрлекләренең мәйданнарын әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымтаның 4 таблицасы нигезендә, СанПиН 2.1.3.2630-10 таләпләрен исәпкә алып кабул итәргә кирәк. Бер ДПО булып берләштерелгән стационар һәм поликлиника (диспансер) җир кишәрлекләренең зурлыгы тиешле нормалар буенча аерым билгеләнә һәм аннан соң кушыла.

5.1.88. ДПО участогын планлаштырганда һәм зоналарга бүлгәндә, функциональ зоналарның катгый изоляциясен сакларга кирәк.

Стационарлар территориясе түбәндәге зоналарга бүленә: йогышлы һәм йогышлы булмаган авырулар өчен дәвалану корпуслары, бакча-парк, патологанатомия корпусы, хуҗалык зоналары һәм инженерия корылмалары зонасы.

Йогышлы авырулар корпусы башка корпуслардан яшел утыртмалар полосасы белән аерылып куела.

Ритуаль зона белән патологоанатомия корпусын палата бүлекләре, шулай ук ДПО янында урнашкан торак һәм җәмгыяви биналар тәрәзәләреннән карап күзәтү булмаска тиеш. ДПО ритуаль зонасына аерым транспорт керү урыны булырга тиеш.

5.1.89. Күппрофильле медицина оешмалары составына кергән йогышлы авырулар, тире-венерология, акушерлык, балалар, психосоматика, радиология бүлекләре аерым торган биналарда урнаштырыла.

Йогышлы авырулар бүлегенә аерым таранспортта (җәяү) керү урыны һәм транспортны дезинфекцияләү өчен ябык мәйданчык күздә тотыла. Тиешле

планлаштырылган изоляция һәм җилләтү автоном системалары булганда, туберкулезга каршы бүлекчәләрдән тыш, алда әйтелгән бүлекчәләрне башка бүлекләр белән бер бинада урнаштыру рөхсәт ителә. Йогышлы авырулар бүлегенә аерым керү урыны каралган булырга тиеш.

5.1.90. ДПО территориясе дәвалау-саклау режимын тәэмин итү ихтыяҗын исәпкә алып төзекләндерелгән, яшелләндерелгән, киртә белән әйләндереп алынган һәм яктыртылган булырга тиеш.

Яшел утыртмалар һәм газоннар мәйданы стационар участогы гомуми мәйданының кимендә 50 процентын тәшкил итәргә тиеш.

Шәһәрдә урнашкан тыгыз төзелеш шартларында, шулай ук составында тернәкләндереп дәвалау һәм карау палата бүлекләре булмаган стационарларда, яшел утыртмалар өлешен һәм бакча-парк зонасы мәйданын киметү исәбеннән участок зурлыгын нормалаштырылган мәйданыннан 10 – 15 процент чикләрендә кечерәйтү рөхсәт ителә.

Агачлар биналарның яктылык керә торган уемнарыннан – 15 метрдан, куаклар 5 метрдан ким булмаган ераклыкта утыртылырга тиеш.

5.1.91. ДПО хуҗалык зонасы территориясендә тәрәзәләрдән 25 метрдан ким булмаган ераклыкта каты япмалы һәм урам ягыннан транспорт керү урыны булган калдыклар өчен контейнерлар мәйданчыгын урнаштырыла. Мәйданчыкның зурлыгы контейнерлар нигезе мәйданыннан һәрьяклап 1,5 метрга зуррак булырга тиеш. Контейнерлар мәйданчыгына чит кешеләр керә алмаска, аның киртәсе һәм түбә япма булырга тиеш.

Медицина оешмаларының калдыклар белән эшләве гамәлдәге норматив документлар таләпләре нигезендә башкарылырга тиеш.

5.1.92. Җитештерү территорияләрендә сәламәтлек саклау учреждениеләре сәнәгать предприятиеләре территориясендә урнаштырыла һәм СК 44.13330.2011 нигезендә исәпләнә.

5.1.93. Даруханәләр аерым торган аз катлы биналарда урнаштырылган, күп катлы торак һәм җәмгыяви биналарның беренче катларына салынган, торак һәм җәмгыяви биналарның янына салынган булырга мөмкин.

Авыл торак пунктларында даруханәләрне ДПО (поликлиникалар, амбулаторияләр һ.б.) белән комплекста бер территориядә яки бер бинада, ләкин аерым керү урыны белән урнаштыру максатка ярашлы санала.

Даруханәләр җир кишәрлеге мәйданын әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымта нигезендә кабул итәргә кирәк.

Ашыгыч медицина ярдәме станцияләрен (ярдәмче станцияләрен), ашыгыч медицина ярдәме күчмә пунктларын, фельдшерлык-акушерлык пунктларын проектлаштырганда, җир кишәрлегенең күләмен, ераклык радиусын, урнаштырылуын әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымта нигезендә кабул итәргә кирәк.

5.1.94. Картлар һәм инвалидлар интернат йортлары йортлар салу өчен билгеләнгән территориядә урнаштырыла.

Проектлаштырганда интернат йортларын тавыш һәм пычрату чыганакларыннан ераклаштыруны күздә тотарга кирәк.

5.1.95. Картлар һәм инвалидлар интернат йортлары сыйдырышлыгы, шулай ук

аларның җир кишәрлекләре мәйданы әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымтаның 4 таблицасы нигезендә билгеләнә.

5.1.96. Интернат йорты территориясе составына түбәндәге функциональ зоналарны кертү күздә тотыла:

яшәү зонасы;

хезмәт күрсәтү зонасы;

карантин бүлеге һәм изолятор белән кабул итү зонасы;

хуҗалык зонасы.

Яшәү зонасында ял итү мәйданчыклары, күләгә төшерә торган түбә япмалар, спорт мәйданчыклары урнаштырыла. Каты авыручылар өчен махсуслаштырылган психоневрология интернат йортларын проектлаштырганда спорт мәйданчыклары күздә тотылмаска мөмкин.

Хуҗалык зонасында автомобильләр кую урыны, казаннар бинасы, кер юу йорты, склад бинаары, ремонтлау остаханәләре, яшелчәләр саклау урыны һәм ярдәмче билгеләнештәге башка корылмалар урнаштырыла ала. Тыгыз территорияләрдә хуҗалык, инженерия бүлмәләрен һәм ярдәмче бүлмәләрне урнаштыру өчен, гамәлдәге норматив документлар таләпләрен үтәү шарты белән, җир астындагы, шул исәптән интернат йортлары бинаалары астындагы урыннардан файдалану киңәш ителә.

5.1.97. Интернат йортын торак пункттан читтә урнаштырган очракта, хезмәт күрсәтүче персоналның яшәү зонасын да күздә тотарга кирәк. Персоналның яшәү зонасы мәйданын түбәндәгечә, кв.метр/урын исәбеннән, участок мәйданына өстәмә рәвештә кабул итәргә киңәш ителә:

10 – 15 – интернат йорт сыйдырышлыгы 100 – 150 урын булганда;

9 – 12 – интернат йорт сыйдырышлыгы 151 – 300 урын булганда;

9 һәм азрак – интернат йорт сыйдырышлыгы 300 урыннан күбрәк булганда.

Персоналның яшәү зонасын учреждение янында аерым транспорт керү урыны белән аерымланган участокта урнаштыру рөхсәт ителә.

5.1.98. Интернат йорты территориясе киртә белән әйләндереп алынган һәм яшелләндерелгән булырга тиеш. Яшелләндерү мәйданы участок мәйданының кимендә 60 процентын тәшкил итәргә тиеш.

Интернат йорты территориясенә кимендә ике транспортта керү урыны каралган булырга тиеш.

5.1.99. Шәһәр һәм авыл торак пунктлары территориясендә яшьләр белән эшләү буенча республика учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр (күппрофильле яшьләр сәясәте учреждениеләре) күздә тотылган булырга тиеш.

5.1.100. Яшьләр белән эшләү буенча республика учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр түбәндәге төрләрдә була ала:

күпфункцияле һәм күппрофильле яшьләр сарайлары (яшьләр йортлары һ.б.);

күпфункцияле яшьләр үзәкләре, шул исәптән ял итү, культура-ял итү, культура-мәгълүмат, культура-спорт, яшьләр-спорт үзәкләре, социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре, социаль-психологик ярдәм үзәкләре, эзләнү эшләре үзәкләре, хәрби-патриотик тәрбия үзәкләре һ.б.

яшәү урыны буенча күппрофильле яшүсмерләр, яшьләр, яшүсмерләр-яшьләр клублары;

профильле һәм тар өлкәдә махсуслаштырылган учреждениеләр (клублар, үзәкләр), шул исәптән яшь гаилә клублары, яшь сайлаучы клублары, компьютер клублары яки интернет-клублар, хәрби-патриотик эзләнү клублары һ.б.

5.1.101. Яшьләр эшләре органнары (яшәү урыны буенча балалар һәм яшьләр белән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы учреждениеләр) белән муниципаль берәмлекләр халкының тәэмин ителеш нормативлары, муниципаль берәмлектә яшьләр санының уртача күрсәткече халыкның гомуми саныннан 25 процент һәм учреждениеләргә йөрүнең норматив проценты муниципаль берәмлектәге яшьләренң гомуми саныннан 10 процент булганда, түбәндәгеләрне тәшкил итәләр:

муниципаль район өчен – бер җирлекара күпфункцияле яки күппрофильле учреждениедән ким түгел;

шәһәр җирлекләре өчен – 1000 кешегә гомуми мәйданның 25 кв.метры исәбеннән яшәү урыны буенча бер күпфункцияле учреждение һәм берничә (икедән ким түгел) күппрофильле клуб яисә төрле тар профильле һәм (яки) махсуслаштырылган учреждение һәм 1000 кешегә учреждениедә даими эшләүче белгечләрнең кимендә ике штат берәмлеге;

авыл җирлекләре өчен – кимендә яшәү урыны буенча бер күппрофильле үзәк (клуб) яки гамәлдәге мәдәният учреждениеләре, өстәмә белем бирү оешмалары һәм башкалар базасында бер яшьләр белән эшләү бүлеге (бүлекчәсе) яисә берничә (икедән ким түгел) төрле тар профильле һәм (яки) махсуслаштырылган яшьләр белән эшләү учреждениесе;

халкы саны 50 мең кешедән артык булган шәһәр округы өчен – ике һәм аннан күбрәк күпфункцияле һәм (яки) күппрофильле учреждение яисә яшәү урыны буенча бер күпфункцияле учреждение һәм кимендә биш күппрофильле клуб һәм (яки) тар профильле яки махсуслаштырылган учреждение.

5.1.102. Күпфункцияле яки күппрофильле муниципаль учреждение (үзәк, клуб) эшчәнлегенең учреждениенең гомуми мәйданына бәйле якынча норматив күрсәткечләре 33 һәм 34 таблицаларда китерелә.

5.1.103. Спорт һәм физкультура-сәламәтләндерү учреждениеләре челтәрен әлеге нормативларның «Рекреацион зоналар» бүлеге («Спорт зоналары» бүлекчәсе) таләпләре нигезендә проектлаштырырга кирәк.

Спорт һәм физкультура-сәламәтләндерү учреждениеләре сыйдырышлыгы, шулай ук аларның җир кишәрлекләре мәйданы әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымта нигезендә билгеләнә.

5.1.104. Сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү предприятиеләрен торак пунктлар территориясендә, яшәү һәм эш урыннарына якынайтып, кагыйдә буларак, иҗтимагый пассажирлар транспорты челтәре белән бәйләнештә иҗтимагый үзәкләр составында урнаштырырга кирәк.

Сәүдә предприятиеләрен урнаштыруны проектлаштырганда, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемаларын эшләгәндә, Татарстан Республикасы һәм аның составына кергән муниципаль берәмлекләр буенча тиешле чорга билгеләнә торган сәүдә объектлары мәйданы белән халыкның минималь тәэмин ителеш нормативларын исәпкә алырга кирәк.

33 таблица

Күпфункцияле яки күппрофильле муниципаль учреждение эшчәнлегенең якынча норматив күрсәткечләре
(гомуми мәйдан – 300 кв.метрга кадәр)

| Учреждениенең гомуми мәйданы | 100 кв.метрдан азрак | 100 – 200 кв.метр | 200 – 300 кв.метр |
|---|---|---|---|
| Шул исәптән техник бүлмәләр | 30 кв.метрга кадәр | 30 – 60 кв.метр | 60 – 120 кв.метр |
| Дәресләр өчен кабинетлар саны | 2 дән ким түгел | 2 – 3 | 3 – 5 |
| Студияләрдә, секцияләрдә, берләшмәләрдә яшь төркемнәренең гомуми саны (учреждение алты көн эшләгәндә һәм төркемнең уртача составы 12 – 15 кеше булганда) | 6 – 10 | 10 – 15 | 15 – 20 |
| Шөгыльләнүчеләр саны | 70 – 120 кеше | 120 – 180 кеше | 180 – 240 кеше |

34 таблица

Күпфункцияле яки күппрофильле муниципаль учреждение эшчәнлегенең якынча норматив күрсәткечләре
(гомуми мәйдан –300 кв.метрдан артык)

| Учреждениенең гомуми мәйданы | 300 – 1400 кв.метр | 400 – 800 кв.метр | 800 кв.метрдан күбрәк |
|---|---|---|---|
| Шул исәптән техник бүлмәләр | 120 – 160 кв.метр | 120 – 160 кв.метр | 240 кв.метрдан күбрәк |
| Дәресләр өчен кабинетлар саны | 5 – 7 | 7 – 15 | 15 тән ким түгел |
| Студияләрдә, секцияләрдә, берләшмәләрдә яшь төркемнәренең гомуми саны (учреждение алты көн эшләгәндә һәм төркемнең уртача составы 12 – 15 кеше булганда) | 20 – 25 | 25 – 60 | 60 тан ким түгел |
| Шөгыльләнүчеләр саны | 240 – 360 кеше | 300 – 800 кеше | 800 кешедән күбрәк (1 кешегә 1 кв.метр исәбеннән) |

5.1.105. Сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү предприятиеләре белән минималь тәэмин ителеш әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымтаның 4 таблицасы нигезендә кабул ителә, шулай ук:

шәһәр торак пунктлары өчен – 25 таблица буенча;

шәһәр торак пунктларында аз катлы йорт салу территорияләре өчен – 28 таблица буенча;

авыл торак пунктлары өчен – 30 таблица буенча.

Сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү предприятиеләренә кадәр ераклык радиуслары түбәндәгечә кабул ителә:

шәһәр округы, шәһәр җирлеге составындагы торак пункт – 26 таблица буенча;

шәһәр торак пунктларында аз катлы йорт салу территорияләре өчен – 29 таблица буенча;

авыл торак пунктлары өчен – әлеге нормативларның 5.1.23 пункты буенча.

5.1.106. Сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү предприятиеләре җир кишәрлекләренең мәйданы әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымта нигезендә билгеләнә.

5.1.107. Торак биналарның эченә һәм эченә-янына салынган сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү объектларын урнаштыру рөхсәт ителә.

Бина эченә һәм эченә-янына салынган сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү объектларын, СК 54.13330.2011 таләпләре нигезендә кешегә тискәре йогынты ясаучы объектлардан тыш, торак йортларның цоколь, беренче һәм икенче катларында урнаштыру рөхсәт ителә.

Җәмәгать туклануы предприятиеләрен торак биналарның йорт яны территоияләрендә урнаштыру рөхсәт ителми.

5.1.108. Җитештерү территорияләрендә ябык һәм ачык челтәрдәге хезмәт күрсәтү предприятиеләре каралган булырга тиеш.

Ябык челтәрдәге җәмәгать туклануы предприятиеләре сәнәгать предприятиеләре территориясендә урнаштырыла һәм СК 44.13330.2011 нигезендә хезмәткәрләр санын исәпкә алып исәпләнә, шулардан:

эшләүчеләр саны сменага 200 дән артык кеше булганда, ярымфабрикатлар белән эшләүче ашханә күздә тотылырга тиеш (нигезләгәндә чимал белән эшләүче ашханәләр күздә тоту рөхсәт ителә);

эшләүчеләр саны сменага 200 кешегә кадәр булганда – тарата торган ашханә;

эшләүчеләр саны сменага 30 дан ким кеше булганда, аш-су бүлмәсен күздә тотарга кирәк.

5.1.109. Җитештерү зоналары һәм торак районнар территорияләре чигендә урнаштырыла торган ачык челтәрдәге учреждениеләр күрсәткечләре 35 таблица буенча эшләүчеләрне исәпкә алу коэффициенты нигезендә яндагы районнар халкына карата исәпләнә. Әлеге территорияләрдәге челтәр составына сәүдә-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар, спорт объектлары, саклык банклары, элемтә бүлекләре, шулай ук автомобиль хезмәтләре күрсәтү офислары һәм объектлары кертелә.

5.1.110. Ваклап сату базарларын аерым җир кишәрлегендә, санитария һәм гигиена таләпләрен саклап, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе белән килештерү буенча проектлаштырырга кирәк.

Базарларны проеклаштыру өчен җир кишәрлеген торак биналарның ишегалды территорияләрендә, җир асты сулары торышы югары дәрәҗәдә булган сазланган урыннарда, чүплекләр, дуңгыз асрау, терлекчелек комплекслары, күн, сөяк эшкәртү предприятиеләре һәм пычрату мөмкин булган башка урыннар янында урнаштыру рөхсәт ителми.

Ваклап сату базарларын урнаштыруны СанПиН 2.2.1/2.1.1.1200-03 таләпләре нигезендә зурлыгы 50 метрлы санитария-саклык зонасын булдыру шарты белән гамәлгә ашырырга кирәк.

Базарны планлаштыру, яңадан планлаштыру һәм төзү ваклап сату базарларын оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы закон актлары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.

35 таблица

Җитештерү зоналары һәм торак районнар территорияләре чигендә урнаштырыла торган ачык челтәрдәге учреждениеләр күрсәткечләре

(яшәүчеләр)

| Чагыштырма: эшләүчеләр (мең кеше) / яшәүчеләр (мең кеше) | Коэф-фи-циент | Хезмәтләр күрсәтү радиусы чикләрендә (1000 кешегә) исәп-хисап күрсәткечләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | сәүдә, кв.метр | | җәмәгать туклануы, урын | көнкүреш хезмәтләре күрсәтү, эш урыны |
| | | азык-төлек сату мәйданнары | азык-төлек булмаган про-дуктлар сату мәйданнары | | |
| 0,5 | 1 | 70 | 30 | 8 | 2 |
| 1 | 2 | 140 | 60 | 16 | 4 |
| 1,5 | 3 | 210 | 90 | 24 | 6 |

5.1.111. Базарларны торак йортлар салу урыннары өстенлек иткән районнарда, сәүдә үзәкләре составында, транспорт магистральләре, шәһәр транспорты тукталышлары, автобус һәм тимер юл вокзаллары (станцияләре) янында урнаштыру киңәш ителә.

Иҗтимагый пассажирлар транспорты тукталышларыннан ваклап сату базарларына җәяү барып җитү ераклыгы 250 метрдан артык булмаска тиеш.

Базар терриориясендәге аралыклар түбәндәгеләрдән артык булмаска тиеш:

400 метр – иң ераклашкан базар объектлары арасында;

200 метр – базарның теләсә кайсы ноктасыннан җәмәгать бәдрәфенә кадәр.

5.1.112. Базарларның җир кишәрлекләре мәйданын проект карары буенча, шәһәр төзелеше торышыннан һәм тәэмин ителешнең исәп-хисап күрсәткечләреннән чыгып кабул итәргә кирәк.

Җир кишәрлекләре мәйданын ваклап сату базарының (комплексының) 1 кв.метр сәүдә мәйданына 7 кв.метрдан алып 14 кв.метрга кадәр, сыйдырышлыкка бәйле түбәндәгечә кабул итәргә кирәк:

14 кв.метр – 600 кв.метрга кадәр сәүдә мәйданы булганда;

7 кв.метр – 3000 кв.метрдан зуррак сәүдә мәйданы булганда.

5.1.113. Территориядән рациональ файдалану мөмкинлеген тәэмин итүне исәпкә алып, базарның чагыштырма сәүдә мәйданын 1000 кешегә 24 кв.метр сәүдә мәйданы исәбеннән проектлаштырырга кирәк.

Бер сәүдә урыны мәйданы әлеге нормативларга теркәлгән 3 нче кушымта таләпләре нигезендә кабул ителә һәм сәүдә мәйданының 6 кв.метрын тәшкил итә.

Гражданнар өчен, 1,5 кв.метрдан ким булмаган сәүдә урыны мәйданы белән тәэмин иткәндә, лотоклардан сезонлы сәүдә итүне оештыру рөхсәт ителә.

Сәүдә урыннары ябык ваклап сату базарында (бинада, корылмада), шулай ук ваклап сату базары территориясенең ачык мәйданчыгында проектлаштырылырга мөмкин.

Авыл хуҗалыгы ваклап сату базарында товар җитештерүчеләрнең товарлар сату эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен сәүдә урыннары саны муниципаль берәмлек администрациясе тарафыннан билгеләнә, ләкин сәүдә урыннарының гомуми саныннан 50 процентган ким булмый.

5.1.114. Ваклап сату базарлары территориясен төзүнең минималь тыгызлыгын кимендә 50 процент тәэмин итәргә киңәш ителә.

5.1.115. Товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) эшчәнлеген оештыру өчен, 2013 елның 1 гыйнварыннан базарларда, авыл хуҗылыгы базарлары һәм авыл хуҗалыгы кооперация базарларыннан тыш (2015 елның 1 гыйнварыннан шулай ук авыл хуҗылыгы базарлары һәм авыл хуҗалыгы кооперация базарларында да), ваклап сату базары урыннары комплексын үз эченә алган бары тик капиталь биналар, төзелмәләр, корылмалар гына кулланылырга тиеш. Күрсәтелгән максатларда вакытлы биналар, төзелмәләр, корылмалардан файдалану тыела. Алда әйтелгән вакытка кадәр капиталь биналар, төзелмәләр, корылмалар белән берләттән вакытлы корылмалардан да файдаланырга мөмкин.

5.1.116. Базарлар хезмәт күрсәтү персоналы һәм килүчеләрнең автомобильләрен вакытлыча саклау (кую) урыннары белән тәэмин ителгән булырга тиеш.

Автомобильләрне вакытлыча саклау урыннары белән тәэмин ителеш исәп-хисабы, ваклап сату базарлары территориясендә автомобиль транспорты кую урыннары (автомобиль кую урыннары) зонасын урнаштыру, шулай ук автомобиль кую урыннарыннан ераклык, аларга керү һәм алардан чыгу урыннары әлеге нормативларның «Транспорт инфраструктурасы зоналары» бүлеге таләпләре нигезендә проектлаштырылырга тиеш.

5.1.117. Җиңел автомобильләрне кую өчен таләп ителгән исәпләнгән машина урыны саны 1 сәүдә урынына яки 10 кв.метр сәүдә мәйданына 1 машина урыны исәбеннән проектлаштырыла.

Иҗтимагый-эшлекле зоналарда урнашкан базарларда сәүдә мәйданы 1000 кв.метрга кадәр булганда, машина урынының исәпләнгән саны 100 таблица нигезендә проектлаштырыла һәм 50 сәүдә урынына 25 машина урыны тәшкил итә.

Аерым торган бинада урнашкан базарны проектлаштырганда, хезмәт күрсәтү персоналы һәм килүчеләрнең транспортын кую өчен мәйданчык автомобиль юлларының машиналар йөри торган өлеше ягыннан күздә тотылырга тиеш. Мәйданчык торак биналарның йорт яны территориясендә урнаштырылырга тиеш түгел. Автомобиль кую урыныннан базарның теләсә кайсы ноктасына кадәр ераклык 400 метрдан артык булмаска тиеш.

Исәпләгәндә автомобильне вакытлыча саклау өчен кую урыннары мәйданы базарның гомуми мәйданына кертелми.

5.1.118. Чүп һәм азык-төлек калдыкларын җыю өчен мәйданчыклар базарның хуҗалык зонасында, сәүдә зонасы чикләреннән 25 метрдан ким булмаган ераклыкта урнаштырылырга тиеш.

5.1.119. Ваклап сату базары территориясе төзекләндерелгән, яшелләндерелгән һәм киртә белән әйләндереп алынган булырга тиеш.

5.1.120. Ваклап сату базарларында су белән тәэмин итү һәм канализация – үзәкләштерелгән, җылылык белән тәэмин итү ТЭЦ, район яки җирле казаннар

бинасыннан, автоном чыганаклардан булырга тиеш.

Ваклап сату базарлары трриториясендә хуҗалык өчен һәм эчәргә яраклы су белән тәэмин итү сүүткәргечләре, аерым чыгу урыннары булган көнкүреш һәм производство канализацияләре системалары, яңгыр канализациясе җайланмасы проектлаштырылырга тиеш.

5.1.121. Торак пунктлар территориясендә авыл хуҗалыгы продукциясе белән ярминкәдә сәүдә итүне оештыру өчен 1000 кешегә 3 кв.метр исәбеннән вакытлы мәйданчыклар күздә тотылырга тиеш.»;

5.2 нче бүлекчәдәге 62 таблицаның 4 нче юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Гомуми белем бирү оешмалары, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары, ял итү, уен һәм спорт мәйданчыклары, балалар мәйданчыклары территорияләре | 25 | 50 | 50 | 50 | 50»; |

5.2.221 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2.221. Автомобиль кую урыннарын башка функциональ билгеләнештәге биналар янына салып, гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларыннан, шул исәптән йокы корпуслары, балаларга өстәмә белем бирү оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары, хастаханәләр, картлар һәм инвалидлар махсуслаштырылган йортлары, А һәм Б категорияләрендәге җитештерү һәм склад урыннарыннан тыш, проектлаштырырга рөхсәт ителә.»;

5.2.225 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир асты автомобиль кую урыннарын гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, шул исәптән йокы корпуслары, балаларга өстәмә белем бирү оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары, хастаханәләр, картлар һәм инвалидлар махсуслаштырылган йортлары биналары астында проектлаштырырга рөхсәт ителми.»;

64 таблицаның өченче юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Фәнни оешмалар һәм проект оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары | Шулай ук | 21 | 29»; |

5.3 нче бүлекчәдә:

5.3.67 нче пунктның икенче абзацында «балалар учреждениеләре, мәктәпләр» сүзләрен «мәктәпкәчә белем бирү, гомуми белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

5.3.103 нче пунктның беренче абзацында «балалар учреждениеләре», «мәктәпләр» сүзләрен тиешенчә «мәктәпкәчә белем бирү оешмалары», «гомуми белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

5.3.134 нче пунктның беренче абзацында:

«балаларга тәрбия бирү буенча гомуми белем бирү мәктәпләрендә һәм учре-

ждениеләрендә», «урта махсус уку йортларында» сүзләрен тиешенчә «гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында», «һөнәри белем бирү оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

5.3.167 нче пунктның 4 нче пунктчасында «мәктәпкәчә учреждениеләр» сүзләрен «мәктәпкәчә белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

6.4 бүлекчәнең 6.4.4 нче пунктында «балалар һәм гомуми белем бирү учреждениеләре өчен» сүзләрен «мәктәпкәчә белем бирү һәм гомуми белем бирү оешмалары өчен» сүзләренә алмаштырырга;

6.8 бүлекчәдә 6.8.2 нче пунктның дүртенче һәм бишенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында;

гомуми белем бирү оешмаларында, балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында, һөнәри белем бирү оешмаларында, интернат-мәктәпләрдә, балалар йортларында һ.б.;»;

7.3 бүлекчәдә:

7.3.13 нче пунктта «балалар мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре» сүзләрен «мәктәпкәчә белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

7.3.16 нчы пунктта «балалар мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, гомуми белем бирү учреждениеләре» сүзләрен «гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

7.3.19 нчы пунктта «балалар мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, гомуми белем бирү учреждениеләре» сүзләрен «гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

7.3.31 нче пунктның «1)» пунктчасында «балалар мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, гомуми белем бирү учреждениеләре, интернат тибындагы гомуми белем бирү учреждениеләре» сүзләрен «мәктәпкәчә белем бирү, гомуми белем бирү оешмалары, интернат тибындагы гомуми белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

7.3.35 нче пунктта «балалар мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, гомуми белем бирү учреждениеләре, интернат тибындагы белем бирү учреждениеләре» сүзләрен «мәктәпкәчә белем бирү, гомуми белем бирү оешмалары, интернат тибындагы белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына теркәлгән 3 нче кушымтада:

2 таблицаның 13 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «13 | Мәгариф | Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары | + | + | + | + |
| | | Гомуми белем бирү оешмалары: | + | + | + | + |
| | | башлангыч гомуми белем бирүче мәгариф оешмалары (башлангыч мәктәпләр) | | + | + | + |
| | | төп гомуми белем бирүче мәгариф оешмалары (төп мәктәпләр) | | + | + | + |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | урта гомуми белем бирүче мәгариф оешмалары (урта мәктәпләр) | | + | + | + |
| | | Балаларга өстәмә белем бирү оешмалары | + | + | + | + |
| | | Мәктәпара уку-укыту-производство комбинатлары | | + | + | +»; |

3 таблицаның икенче юлында:

